РӘИС САФИН



Йөрәк парчалары

Шигырьләр һәм поэмалар

SHAMS
КАЗАН
2012

УДК 820/89 (470).0
ББК 84 (2 Рос = Тат) – 6
С 21

Рәис Сафин. Йөрәк парчалары. – Казан:
С 21 РИО ГУ «РЦМКО», 2012. – 256 б.

Бу китапны бастырып чыгаруда ярдәм иткән улым Расихка олы рәхмәтләремне белдерәм.

© Сафин Р.Г., 2012
© РИО ГУ «РЦМКО», 2012



Шатлык бүләк итә алуда, башны гамьгә сала белүдә чын бәхет

Табигатьнең кодрәт, могҗизасын
Бер күргә Җиргә килерлек!

ди дөньяга ачык күзләрс белән карап торучы Рәис Сафин. Ә аңа шактый күргә, шактый авырлыклар кичергә туры килде бу тор-

мышта. Ачы «лаеш шулпасы»н да, татлы «тормыш боткасын» да татып карады егет.

Шуңа да шагыйрь бөтен тавышына, үзен хаклы санап:

Яшәүнең асылы шулдыр:
Барның рәхәтен күрү,
Эшләп тапкан хәләл малның
Хуҗасы була белү,

— дип әйтә.

Рәис — Арча ягының Субаш-Аты авылында туып-үскән егет. Әйе, мин аны чынчынлап егетләр затыннан саныйм. Чөнки дөнья, тормыш аңа өйгән гамь-хәсрәтләрне күбебез күтәрә алмас иде. Ә Рәис чыныга гына төшкән. Өстәвенә, әле менә дигән шигырьләр, поэмалар, проза һәм публицистик мәкаләләр яза, ил кайгысын кайгырта, аталарча яшь буынны тәрбияли, милләт өчен, аның бүгенге көне һәм киләчәге өчен кайгыра, тормышта туган кыен хәлдән чыгу юлларын эзли, таба-күрсәтә белә.

Рәис — бүгенге, хәзерге заман шагыйре. Тормышта йомшак күңелле, үтә дә зыялы бу өлкәнебез — шигырьләре, поэмалары, мәкаләләрендә үтә дә кырыс, компромиска бармый торган милли батыр. Милләт мәнфәгатьләрен кайгыртып, халкыбыз өчен янып, өтәләнеп яши Рәис ага үз иҗатында.

Күз алдымнан үтә бабамнарның
Кан-яшь түккән мәхшәр заманы.
Ыңгырашып ауган манаралар,
Тынып калган җомга азаны.

Рәиснең шигырьләрен укыганнан соң күңелдә арзу-өмет туа, ышаныч нык ый, киләчәкнең офыклары якты рыш, аязып киткәндәй була. Яшисе, эшлисе, милләткә файда китерәсе килә башлый. Үзеңнең иҗатыңа да җитдирәк күздән чыгып карый башлыйсың.

Рәис халкыбызга якын, аңлаешлы тел белән яза, халык күңелен ачып сала белә, халык кабул итәрлек чын әсәрләр иҗат итә. Шуңа күрә аның мин эшләгән «Шәһри Казан» гәзите битләрендә чыккан шигырьләрен дә күзәтеп, укып рәхәтлек алучыларның гаскәре дә шактый зур, күләмле гаммә. Нинди генә тема-мәүзукны күтәрмәсен, Рәис киң колачлы, тирән фәлсәфәи нәтиҗә ясый белә. Аның мәхәббәте дә, анасы да, атасы да бер кемнекенә охшамаган үзенчәлекле шәхесләр, ләкин Рәис аша без һәммәбез

үзебезне, үз язмышыбызны, үз тормышыбызны күрәбез, үзебезнең җаныбыз аша үткәрәбез. Кыскасы, Рәис хәтере аша үзебезнең хәтеребез уяна, үз үткәннәребез җанлана, үз киләчәгебез ачыклана, яктыра төсле.

Рәис халык мәнфәгатен кайгырткан шигырь, поэмаларында көчле. Бигрәк тә «Моң», «Ана», «Нәсихәт» кебек киң колачлы әсәрләре күтәрә аның иҗатын. Сөекле яры, якты дөньядан бакыйлыкка ир-тәрәк күчкән хәләл җефете дә үзәк өзгеч сурәт булып килеп баса аның иҗаты аша күзалдына. Һәм, гомумән, Рәис тирән уйлый, киң колач белән йөзә белә иҗат дәрьясында:

Җилләр исә, сабый үсә,
Әнисе кочагында.
Бәхетле булыр, иншалла,
Тәүфыйгы бар чагында.

Җилләр исә, бала үсә,
Хисләре тула, ташый.
Акыллылар акыл белән
Тормышын кора башлый.

Җилләр исә, гомер үтә
Рәхәттә, газапта да.
Үтә читлек эчендә дә,
Хөрлектә — азатта да.

Җилләр исә, куәт китә,
Бәхилләшер көн җитә.
Җилгә очмаган гамәлләр
Озын гомерле итә.

Җилләр исә, җилләр тарый
Картлыкның энҗе башын.
Әманәт булып безләрдән
Игелек кенә калсын!

Мин шагыйрьнең бу шигырен аның тормыш һәм иҗат юлында торган юнәлеш бер-үче маягы дип саныйм.

Рәиснең бу китабын кулына алган укучы үзенә бик күп әсәрләр табар, укыр, ләззәтләнер, гыйбрәт алыр.

Талантларга бай, Г.Тукай, Ш.Мәрҗани, М.Галәү, Г.Бәширов, Г.Ахунов, М.Мәһдиев һәм тагын да дистәләрчә талантлы язучы — каләм остасын милләтебезгә бүләк

иткән Арча иле безгә тагы бер талантлы шагыйрь бүләк итеп куандыра.


Моннан артык шатлык тагы булырмы?! Кеше бит ул сүз белән яши, сүз аны куандыра, сүз бәгырен өзә, сүз сугыштыра, сүз татулаштыра.

Болар барысы да Рәиснең иҗатына хас нәрсәләр, һәм аның иҗади куәтен дәлилләүчеләр дә.

Шунысы да шатлыклы, куанычлы. Рәис үзе үк вакыйга ул, әдәбиятта вакыйга.

Әхмәт Гадел

I



Васыять

Васыять

Сафьян тышлы Коръән тотып,
Әнием төшкә керде.
Болгар бабаларыңнан, дип
Ошбу Китапны бирде.

Һәм әйтте васыять итеп:
Милләтем бәйсез булсын!
Асыл ирләр вә кызларым
Халкыма хезмәт кылсын.

Эшләнгән һәр эшләреңдә
Изгелек булсын юлдаш.
Бәхетле итмәс һичкемне
Хәрам маллар, хәрам аш.

Коръәнле халык яшәсә,
Илгә бәрәкәт иңәр.
Ул илдә яшәгән халык
Бар авырлыкны җиңәр.

Онытым Шамилгә

Торып-торып уйланам да, сыкранам,
Аяныч хәлемне күреп, ут янам.
Җиргә килеп, ни игелек кылдым мин?
Кемнәр белән, нинди тормыш кордым мин?!

Яшәүләрем, эш-гамәлем дөресме?
Әллә яман юл-сукмакка керешме?
Уен итеп карадыммы тормышка,
Минме гомер елгасында йомычка?!

Гореф-гадәт, динем илемдә тынды,
Чит куенга бала-оныклар шылды.
Буыннарның бәйләнеше өзелде.
Әби-бабай учагыннан бизелде.

Корт ашаган агачтай калдык корып,
Урыс телле балалар алды сырып.
Ата-баба бүләк иткән әманәт,
Онытсаң әгәр — милләткә хыянәт.

Нишләргә дә белми бүген баш орам,
Дин-имансыз варислар белән торам.
Җиһан хәрам, фәхешлек белән тулды,
Оят-намус, хәләл гамәл онытылды...

Улым, Син ышанычым, синдә өмет,
Бул мөселман! Бул үзебезнең егет!
Алла бирсен сиңа тәүфыйк-сәгадәт,
Тик иманлы булып яшәү чын рәхәт.

Өеңдә Коръән нуры-моңы булсын,
Әби-бабам әләмс балкып торсын!
Бу минем иң мокатдәс васыятем,
Нәсел-ыру әманәтен сиңа әйттем.

Күңел очынганда

Далаларны, чүл, кырларны иңләп,
Төрки егетләре ат чапкан.
Скиф, хәзәр, болгар, кыпчак, һуннар
Кыйтгаларны кочып ил тоткан.

Кемдер әйтер: «Ул заманнар узган,
Кәперәймә, итмә тантана».
Әмма булган алар! Әнә, кемсә
Булмаганы белән мактана.

Хак варислар — без — татарлар калдык,
Хәтер калды, булып әманәт.
Төрки бабаларның ниятенә,
Әманәткә итмик хыянәт.

Канга — кан, үлемгә — үлем безгә,
Афәтле юл, милли фаҗига.
Яшен яшнәмичә күк күкрәми,
Милләтебез калка, хәл җыя.

Борынгыдан насыйп көмешебез —
Иртеш белән Дунай арасы —
Казаныбыз — илнең башкаласы,
Безгә анда мәңге буласы!

Соң түгел!

Ябырылды дошман өстебезгә,
Кара болыт яңты һаваны.
Асу-кисү, суеш-үтерештән
Кан туфаны басты каланы.

Азаматлар ауды яу кырында,
Идел-Йортны саклый алмады.
Кара болыт тора өстебездә,
Җирдә яшәр урын калмады.

Ай-кояшсыз яшәү, ай-һай, җайсыз —
Зәгыйфьләндек, төсләр үзгәрде.
Өметсезлек пәрдәләре әллә
Капладымы безнең күзләрне?

Таратырга кара болытларны
Соң түгел бит әле бүген дә...
И, Татарым! Яшен ташы булып,
Зил-зиләләр уйнат күгеңдә.

Алга, иреккә табан!

Мәш килә шаһгаличеләр,
Сукыр черкиләр сыман, —
Авызга, күзләргә кереп
Теңкәдә уйный торган.

Сәнәктән көрәк булганнар
Йөрмәкче булып әтәч.
Солтанов солтан булмакчы,
Госсоветка кермәгәч.

Садыйковның оны чыкмый,
Тегермәне ватылган.
Чалмасын салган мөфтинең
Вәгазе онытылган.

Шовинист агайның пәшә —
Ялагай татар улы.
Татарны татарга каршы
Уйната Мәскәү кулы.

Этләр өргәннән курыкмый
Юлыннан бара кәрван.
Әй, туганнар, кәрванчылар,
Алга, иреккә табан!

[1] Пәш — пешка, шаһматта

Биш тирәк

* Яшьләр үзәге тукталышы янында бер тамырдан чыгып, биш тирәк үсеп утыра. Алар миңа Казан, Кырым, Себер, Әстерхан, Касыйм мәмләкәтләрен хәтерләтте.

Киң аланда, зур түгәрәк ясап,
Бер тамырдан үскән биш тирәк.
Колач җитмәс кәүсәләрен күреп,
Сокланмаган кеше бик сирәк.

Ирек биреп игезәк туганына
Киерелеп баскан һәрбере.
Алыпларның гайрәтедәй ташып,
Тулып ашкан тирәк егәре.

Күккә ашкан таза кәүсәләрнең
Ботаклары киткән җәелеп.
Нинди куәт кирәк тамырларга
Биш бертуган тал-тирәкләр шулай
Торсын өчен җиргә береген!?

Өермәләр, тузгып-бөтерелеп,
Ябырыла килеп аларга.
Җил-бураннар әнҗе яфракларын
Очыртмады йолкып кайларга?!

Киң аланда бергә кочаклашып,
Күкрәк киереп үсә биш тирәк.
Давылларга каршы торыр өчен,
Бердәм булу, дуслар, һай, кирәк!

Юк!..

И, халкым, кем дип эндәшим?
Син — болгар, татар, бигер?
Тик түгел төмут сакчысы,
Һәм түгел син чит бер ир.

Юк, түгел син, бер килмешәк,
Үз илендә — син хуҗа!
Тик нигә синең иңнәрдә
Һаман да яши нужа?!

Юк, түгел син зәгыйфь милләт!
Булса да җаныңда чир.
Бу газиз халкыма, зинһар,
Илаһым, сабырлык бир!

Гарасат

Күкнең йөзе аяз иде, зәңгәр иде,
Офыкларда кысыр ак болытлар йөзде.

Күләгәләр каплап алды кояш нурын,
Саташтырып мәхлукларның барыр юлын.

Пәйда булды ястык кадәр кара болыт,
Яшеннәре ялт-йолт итте, кылыч булып.

Давыл кубып, иген егып ява яңгыр,
Күк күрәүдән җирләр тетри шатыр-шотыр.

Ил өстендә җил, өермә бөтерелә,
Бар кануннар ятка тәңгәл китерелә.

Һәр тарафта кәгазь оча, йөзгә бәреп,
Мөстәкыйльлек бетте, булмый иркен йөреп.

Зил-зиләдән түбә оча, йортлар ава,
Йөз меңләгән җан иясе мәхрүм кала.

Залим затлар бу афәттән файда ала,
Башкаларга һәлакәтле тозак сала.

Кем — саламга, кем бүрәнәгә тотына,
Кайсы — сатып, кайсы сатылып котыла.

Кемдер өермә алдында койрык болгый,
Берәүләре яла ягa, әләк юллый.

Ә кемнәрдер җил-давылдан гыйбрәт ала,
Киләчәккә ышанычлы нигез сала.

Ил язмышы болганмасын, чолганмасын,
Җил-давылдан барыр кыйбла югалмасын!

Үзгәртәсе иде

Төп канунга саллы кулын куеп,
Илбашлары илгә ант бирә.
Канун Коръән түгел, антны эчкән
Сүзен тоталмасын ил белә.

Кануннардан шуңа курыкмыйлар,
Илне-җирне көн-төн талыйлар.
Канун язган затлар, күрә торып,
Хакыйкатьне ялгыш саныйлар.

«Динем өчен түгел, көнем өчен», —
Диеп яши күбе, бичара.
Халкын, илен, үзен сата, әгәр
Мал чәлергә чыкса бер чара.

Кардәшенә, илгә пычрак ата,
Өреп ята кайсы чит җирдә.
Тыны бетсә, ике аршин җирсн
Бирәсе юк ятлар, мескенгә.

«Чир китәр ул, гадәт китмәс», — диләр,
Үзгәртәсе иде гадәтне!
Илсез-җирсез, мал-мөлкәтсез калдың
Ник алмыйсың, татар, гыйбрәтне?

Алтын-көмеш аш булмаган кебек,
Чын чикләвек үсми имәндә.
Үз милләтең белән яшәү — фарыз,
Бәхет-тәүфыйк — изге Коръәндә.

Өмет итик

Ашар-әчәр ризык, үтәсе юл
Җан иясен йөртә җиһанда.
Җәһәннәмне җәннәт итә кеше
Мәхәббәт һәм акыл булганда.

Мәхәббәт һәм акыл көнкүрештә —
Пар канаты, диләр, кешенең.
Бәхетле ул, әгәр ачкыч таныса
Күңеленә үзе ишенең.

Тик мәхәббәт, кояш кебек балкып,
Сихри хискә урый иркәсен.
Тик илаһи акыл мәхәббәткә
Белсен кайчан кодрәт бирәсен.

Өмет итик — акыл, мәхәббәтнең
Безнең белән янә туасын,
Сөю дигән могҗизалы хиснең
Ике дөньяда да буласын.

Өмет итик — гөнаһ, хаталарны
Хак Тәгалә гафу кыласын.
Өмет итик — газиз җанкайларның
Мәңгелектә бергә буласын...

Әй, бу гомер...

Әй, бу гомер!.. Бик тиз үтеп бара,
Фанилыкның җитеп чигенә.
Бер киселгән агач кабат үсми,
Кем өчен дә гомер бер генә.

Яшь чагыңда гомер бетмәс сыман,
Ул мәңгелек кебек тосла.
Ләкин еллар галәм гөмбәзеннән
Яфрак булып җиргә коела.

Гомер юлы шома гына бармый,
Хәрамгә дә кулың сузасың.
Оят, намус кайчак читтә кала,
Тыелганны «күрми» узасың.

Дөнья куып, нәфес колы булып
Йөгерәсең, аттай чабасың.
Биргәненә шөкерана итми,
Әзеннән дә колак кагасың.

Барысы да бәйле бу гомердә
Үзең кылган эш вә гамәлгә.
Яхшысы да, яманы да сица
Кире кайта шул ук кимәлдә.

Беләм, бер көн галәм гөмбәзеннән
Соңгы яфрак төшәр өзелеп.
Гомер юлы гамәл дәфтәрендә
Энҗе кебек калсын тезелеп...

Иншалла

Мәхшәр көне икән, имеш,
Бинһая мәйданда,
Гамәл дәфтәрләрен тоткан
Шыгырым халык вәйранда.

Булат кылычтан да үткен,
Кылдан да нәзек күпер.
Корбан чалган үтә аны,
Аллаһка әйтеп шөкер.

Тавыш иңде: «Илләллаһ, дип
Тәүбәгә килгән кемсә,
Җәннәтемә керә алыр
Сират күперен үтсә».

Камил акылына килеп,
Уянды татар улы.
Тар сират күперен кичеп,
Барасы аның юлы.

Үзең төшәсең

Тиктомалдан кызып китте
Кызылборын, арык зат.
«Кавказ чырайлы» халыкка
Зәһәрен якты кат-кат.

«Чечеңнәр, — ди, — ваһһабилар,
Алар — бандит, террорист.
Аларны кырып бетереп,
Куярга вакыт крест».

Төкрек чәчә, «мат» өләшә,
Очының торып басты.
Чыгырыннан чыккан сәрхүш
Егылып башын ватты.

Аяк-куллар да имгәнгән,
Ике күзен кан баскан.
Зәһәреннән нуры сүнгән,
Төс-битеннән җан качкан.

Кара йөрәк ыңгыраша,
Тишек баштан кан ага.
Чокырга үзең төшәсең,
Казысаң да башкага.

Авылым

Асыл ташлы беләзектәй,
Чишмәләр алган урап.
Көмеш сулы инешләреңә
Агалар тирәң буйлап.

Субаш-Атым, Субаш-Атым —
Иделем чишмә башы.
Авыл уртасында мәчет —
Халкымның йөзек кашы.

Синдә — срак бабаларның
Әманәт нигез ташы.
Кендек каным тамган җирем,
Гомеремнең юл башы.

Субаш-Атым, Субаш-Атым —
Иделем чишмә башы.
Изге туфрагыңда калсын
Догалы каберем ташы.

Асылыңа кайт, татар!

«Әйт, авылым, моң кайда соң,
Моң кайда соң, әйт, урам?!»
Р.Чурагулов

«Моң кайда?» — дип, урамнардан
Моң эзли безнең татар.
Катнаш гаиләдән чыккан,
Нәсел тамырын онытқан
Кем диеп үзен атар?

«Моң кайда?» — дип, урамнардан
Моң эзли безнең татар.
Илен, телен, денен саткан,
Тарих юлында адашкан
Кем диеп үзен атар?

«Моң кайда?» — дип, урамнардан
Моң эзли безнең татар.
Тарих чоңгылына батар,
Үзен югалтса татар...
Динең, телең, моңың белән
Асылыңа кайт, татар!

Табигатьнең үзе, гел үзе...

Күкнең йөзен кара болыт япты,
Шомлы тынлык сөрә һәр тараф.
Лепелдәшми агач яфраклары,
Һава бөркү, дөнья битараф.

Давыл купты. Чүп-чар өермәсе
Күккә ашты, үреп багана.
Коеп яуган яңгыр ташкыннарын
Куенына ала Җир-Ана.

Искән җилләр тарта-йолкый торгач,
Кара болыт чите ертылды.
Күк йөзеннән шулчак, яшь килендәй,
Кояш көлде, нурлар бөркелде.

Бөтен дөнья, барлык җан иясе
Сулыш алды, калды бушанып.
Гөл-чәчәкләр таҗы керфек какты,
Яшәү дәвам итте сафланып.

Бураннары, яңгырлары белән,
Дөнья матур, дөнья сөйкемле.
Мәңге серле, сихри хатын-кыз да
Табигатьнең үзе шикелле.

Акыл белән яшәргә

Һәркемнең бар үз тормышы,
Һәр агачның — җимеше.
Һәр чиләкнең үз капкачы,
Һәр өлешнең көмеше...

Һәркем үзенчә көн күрә,
Сәләт хәленә карап.
Акыл иясе булып та,
Һәркемгә булмый ярап.

Кемгә кояш та ошамый,
Елмаеп балкыса да.
Кем якты айга да гашыйк,
Җылысы булмаса да.

Кемнәр игелек кылудан
Җанына ләззәт ала.
Җан кыючы булып кемнәр,
Тарих битендә кала?!

Тегесе дә, моңысы да
Дөньяда сынау үтә.
Аллаһ хөкеменә китә,
Кемнедер җәннәт көтә...

Алла безгә гомер биргән,
Тел ачкычы — дәшәргә.
Һәр эшнең чамасын белеп,
Акыл белән яшәргә.

Әни талган үлем йокысына

Әни талган үлем йокысына,
Тәсбих тотып ике кулына.
Әни, уян... Уян инде, әнием,
Мәтрүшкәле чәең суына.

Әни талган үлем йокысына,
Сагыш кунган ап-ак йөзенә.
Әллә ниләр бирер идем аның
«Улым!» — дигән назлы сүзенә.

Әни талган үлем йокысына,
Ил рәхмәтен алган табибә.
Мәхәлләнең тансык абыстае,
И кадерле Әнием, Хәбибә.

Әни талган үлем йокысына,
Йөрәгемдә хәсрәт ярасы.
Әни, уян! Аллаһ хозурына
Үзем генә булдым барасы...

Йомычка

Дулкыннарын дәрья ярга кага,
Яр буйлары ап-ак күбектә.
Ыгы-зыгы килгән шау дулкыннар
Синең кебек, минем кебек тә.

Яр буенда чүп-чар чәчелеп ята,
Сута төшә, суда чайкала.
Дәрья үзен ярга бәрә-бәрә
Госелләнә, балкып, саф кала.

Алар — анда, мин — биредә, диеп,
Үпкәләмә һич тә язмышка.
Кайда чайкалсак та без — кешеләр,
Нәфесең колы булып ялгышма!

Кыз-әби

Бер кыз-әби үлем түшәгендә
Аңын җуя, ала саташып.
Әле урман кискән кебек итә,
Әле окоп казый, туң чукып.

Күкрәгенә кысып назлый, сөя
Өстендәге сырган юрганын.
«Габдуллам, мин Сине көтәм» — дия,
Яу кырында ятып калганын.

Елмаюдан йөзе балкып китте,
«Алчы мине, — дия, бер кочып».
Әби ята хыял кочагында,
Ахирәткә китте җан очып.

Дөнья булгач...

Дөнья булгач, төрле чагы була...
Ызгышып та кайчак аласың.
Язмыш сине кайчак курчак итә,
Җиде юл чатында каласың.

Дөнья булгач, төрле чагың була,
Бер туясың чуар тормыштан.
Кешеләргә бер бушанып алу
Бирелгәндер шуңа тумыштан.

Диңгезләр дә кайчак пакъләнәләр,
Ярга атып җыен чүп-чарны.
Диңгез кебек кайнап алу, бәлки,
Яңартадыр кабат иманны...

Бар да әйләнештә...

Барысы да Җирдә әйләнештә...
Төн артыннан балкып көн туа.
Яз килүгә, сабан тургайлары
Күк иленнән җиргә моң коя.

Барысы да Җирдә әйләнештә...
Фанилыкта сынау үтәбез.
Сабый булып Җиргә киләбез дә,
Мәңгелеккә Җирдән китәбез.

Барысы да Җирдә әйләнештә
Безнең гомерләр дә, әлбәттә...
Дөньялыкта изге гамәл кылган —
Иншә Аллаһ булыр җәннәттә.

Тудырган да, үстергән дә...

Урманнарга барам, сихәт алам,
Өшетсә дә салкын, уралып.
И, шәфкатьле, мәрхәмәтле урман,
Көн күрәбез синнән юл алып!

Газиз әнкәм кебек син илаһи —
Әнием дә синең шикелле.
Сез ул чиксез кодрәт ияләре,
Икегез дә күркәм, сөйкемле.

Тудырган да, үстергән дә — сез ич,
Изгелеккә исең китәрлек.
Игелекле эчке матурлыкның
Бәрәкәте мәңге җитәрлек.

Кышкы урман ак күлмәген кигән,
Күркәмлеге балкый йөзендә.
Хатын-кызның төсе үзгәрсә дә,
Гүзәллеге кала үзендә.

Бирешмиләр алар, тормыш шәмен,
Аллаһ биргән алар кулына.
Тышта февраль. Салкын. Ләкин урман
Сәфәр чыккан яңьлек юлына.

Язмышлардан узмыш...

Суга төкермә, дигән бабамнар,
Бел, шул суны үзең эчәрсең.
Саф су эчеп, үз татарың белән
Гомереңнең юлын кичәрсең.

Якын итә ятлар яланганда,
Тормыш өчен кирәк үз кешең.
Ятларга син — эткә аткан сөяк,
Милләтеңә — алтын, көмешсең.

Язмышлардан узмышлар юк, диләр,
Ихтыярсызлыктан аклану.
Аклануга сәбәп бирмик дисәк,
Хаталардан кирәк саклану.

Аллаһ безгә Коръән, дин иңдергән,
Мөселманны саклап, якларга.
Узмыш булыр Аллаһ язганыннан
Кыз-уллӑрны бирсәк ятларга.

Туй-никахлар булсыннар мөбарәк,
Бисмиллалы табын — түгәрәк, —
Түгәрәктә үз өммәтең белән
Яшә кешем, яшә бергәләп!

Аш ашадым, яшь яшәдем...

Аш ашадым, яшь яшәдем,
Үлемне хак саныймын.
Аллаһның бар һәм берлеген,
Тиңсезлеген таныймын.

Җәннәт түрен өмет итмим,
Ишек төбе дә ярар.
Туганнарым күрермен дип,
Күзләрем түргә карар.

Иркәләр идем үзләрен,
Мәхәббәтемә төреп.
Ата-анам, җефетемне
Сөеп, кадерен белеп.

Сый-хөрмәт күрсәтер идем,
Төрле җимешләр куеп.
Өчпочмакны, ипикәйне,
Һинд чәйләрен, куанып...

Аш ашадым, яшь яшәдем,
Эшем дөньяда кала.
Кеше үзе белән фәкать
Гамәлен генә ала...

Тау гомере телəп

Таулар белəн таулар күрешмиләр,
Кеше белəн кеше — очраша.
Акыл белəн — акыл, хис белəн хис
Табышканда җаннар сайраша.

Тау астыннан чыккан саф чишмәләр
Инешләргə килеп кушыла.
Җан тартканнар, ихлас яратканнар
Дуслар була, ишкə куш була.

Авыр шөгыль — тауга менүләре,
Урап үтə аны бүтəннəр.
Тик синең күк кыю ир-егетлəр,
Тəвəккəлləр тауга менгəннəр.

Болытларга ашкан кыя-таулар
Тоташканнар кочып бер-берен.
Яшик əле, дустым, җанга салып,
Таулар холкын, таулар гомерен.

II



Сəер төш

Җирдәге кояш

Су өстендә — әнҗе балкышлары,
Нурларыннан күзләр камаша.
И, хатын-кыз, йөзләреңдә синең
Аллаһ нуры иңгән тамаша.

Чәчәкләрдән үргән такыялар
Гүзәллеге балкый йөзеңдә.
Аллы-гөлле салават күперспең
Сихри яме серле күзеңдә.

Кунар булып кыйгач кашларыңа
Керфекләреңә канат кагына.
Бер ягымлы сөеп елмаюың
Мәхәббәтнең илтә багына.

Офыкларның шәфәкъ алсулыгын
Иреннәреңә ялкын иткәннәр.
Күңелләрне өтә, Мәҗнүн итә,
Егет була аны үпкәннәр.

Чәчләреңнең йөгерек дулкыннары
Җан капкасын килеп кагалар.
Йөрәкләрне әсир, гашыйк иткән
Толымнарда яшерен тылсым бар.

Тиңдәшең дә, көндәшең дә юктыр
Син — илаһи камил могҗиза,
Пәйгамбәрләр, мәшһүр даһиларга
Яшәү, акыл биргән Газизә.

И, хатын-кыз, үзең — илаһи зат,
Кодрәтле зат, җирдә ут яккан, —
Аллаһ сине изге Җир-Анага
Хуҗабикә итеп яраткан.

И, хатын-кыз! Гүзәллекләр таҗы,
Кешелекнең җирдә Кояшы.
Нурлар сибеп, син балкысаң гына
Тормышыбыз ләззәт дөньясы...

Мәхәббәттә генә гөнаһ юк...

Газапланма бәгърем, газапланма,
Елмаюың күптән ясалма.
Чәчем белән җирне себерсәм дә,
Була алмам, ахры, багалма.

Күзләреңнең моңсу карашлары
Төбәлгәннәр үзгә торакка.
Торганында синең һич гамең юк,
Әйтерсең лә, килдең кунакка.

Сагыну-сагыш, нидер юксынудан
Шашар хәлгә кайчак җитәсең.
Уйларыңның очына чыга алмый,
Башың җуеп, изрәп китәсең.

Сулар кире акмый, үткән — кайтмый,
Хаталарны булмый төзәтеп.
Чирләр китеп, гадәт китмәсә дә,
Яшәү кирәк холкың үзгәртеп.

Ни файда соң, үзең өстен калып,
Сөйгәнеңне җуйса мин-минлек?
Үз-үзеңне алдап, ачу саклау.
Яшәү бирмәс җанга иминлек.

Тик мин дә бит көчләп яр булмадым
Мәхәббәттә, беләм, гөнаһ юк.
Никах безне кавыштырган икән,
Ул никахка кылма хилафлык.

Минем иркәм

Минем иркәм гаҗәп күркәм,
Йөзе көләч, сөйкемле.
Бер карасаң, башкалардан
Аерылмый шикелле.

Бер карасаң, бит очына
Шәфәкъ аллыгы кунган.
Сөйкемле булсын дип Ходай
Нәни миң төртеп куйган.

Офыкларның алсулыгы
Гүя йөзенә сыйган.
Әйтерсең, күңел күгендә
Җәйге таң ата сыман.

Нур бөрки сихри күзләре,
Зөһрә йолдызы булып.
Килешле гәүдә-сыннары
Ай кебек килгән тулып.

Салават күпере кебек
Сөрмә тарткан күз-кашы,
Ихлас елмаюларында
Балкый күңел кояшы.

Минем иркәм сабыр, тыйнак,
Эчке дөньясы күркәм.
Эчке дөньясы күркәмнең
Йөзе дә гүзәл икән.

Соңласа...

Күк күкрәде. Ут-ялкынлы яшен
Диңгез төбен сугып сындырды.
Биниһая төпсез кара упкын
Чал диңгезне эчкә суырды.

Җир-ананың ярсып тетрәвеннән
Таеп китте хәтта күчәре.
Котырынып өскә калкып чыкты
Катламнарның шашкын егәре.

Җир кайнады упкын казанында,
Йә җәелде, йә ул кысылды.
Көч-кодрәтен җыеп, дәһшәт белән
Җир эндәште: «Мин бит тылсымлы!..»

Давыл купты. Дулкын өермәсе
Бөтерелеп ярга йөгерде.
Ябырылып килгән цунамилар
Йорт-җирләрне ватып җимерде.

Тамырлары белән умырылып,
Ыңгырашып ауды урманнар.
Илаһи көч афәтенә тарыр
Кануннарын бозган оланнар.

Йөз-меңнәрне бер мәл һәлак итә,
Кыйтгаларны иңләп су баса.
Кешелекне каты җәза көтә,
Тәүбә итәренә соңласа.

Сөер төш

Ире куенында изрәп,
Ханым сәер төш күрде.
Шәл якалы асыл тунын
Ялгыш кемгәдер бирде.

«Кайда минем туным?» — диеп,
Өзгәләнә, ут йота.
Караса, иң башларында
Өтек иске тун ята.

«Үз тунымны китерегез,
Алыгыз, — ди, — монысын.
Җаным-тәнем тойсын тәмен
Үз тунымның җылысын».

Төшен юрады: асыл тун —
Ташлап киткән үз ирем,
Өтеге — бергә торганым,
Наз, игелек күргәнем.

«Үлгән сыер сөтле була», —
Диюләре хак икән.
Тәүге мәхәббәт гомерлек
Сихри бер тылсым икән...

Бел

Купшы тамчы гөлләреңне
Сулар сибеп үстерәм.
Чәчәк аткан чакларында
Гөлләрдә сине күрәм.

Шул гөлләргә әверелеп,
Яшисең мине сөеп,
Фанилыкта гомерләрнең
Мизгел икәнен белеп.

Балкып торган таҗ-чәчәкләр
Моңсу гына өзелә.
Чәчәктәй гомер өзелү —
Үзәкләрне өздерә.

Дистә еллар узып бара,
Төзәлми һаман яра.
Сагыну-сагыш, юксынудан
Йөрәгем парә-парә.

Ялгызлык

Кысыр болыт кебек араланып,
Бер ялгыз каз калган урамда.
Әйтерсең ул үзенең парын җуйган
Җил-давылда, кышкы буранда.

Каңгылдап та куя, аннан тына,
Үз җанына урын табалмый.
Каерылып төшкән уң канатын
Иңнәренә җыеп салалмый.

Бәбкәләре көзен таралгандыр,
Беръялгызы калган, бичара.
Кыйгак-кыйгак, парын эзли буйдак,
Бу мескенгә кылмак ни чара?

Җылак көзнең яңгырлары сыман
Сагыш тама моңсу күзләрдән.
Өмет өзми, ышанычын эзли
Бергә тормыш иткән эзләрдән.

Җил-буранлы шәрә төнгә каршы,
Бер ялгыз каз калган урамда.
Парын җуйган шул каз кебегерәк,
Калма икән өлкән булганда.

Хуш — бәхил бул

Кайгылардан вакыт дәва, диләр.
Кем кайгыдан мине аралар?
Вакыт үткән сасн ныграк әрни,
Әҗәл уты тигән яралар.

Кайгылардан вакыт дәва, диләр.
Мәхәббәтнең бармы дәвасы?
Вакыт үткән сасн тирәнәя
Йөрәгемдә сөю ярасы.

Кайгылардан вакыт дәва, диләр.
Вакыт йомар, диләр, кайгыңны.
Дәва да юк, дару, чара да юк,
Кабер йомса сөйгән ярыңны.

Кайгылардан вакыт дәва, диләр.
Ялгызлыгым чәнчи бәгыремне.
Сагынудан җаным сыкранганда
Ятып кочам салкын кабреңне.

Кем уйлаган синсез калырмын дип,
Яшәрмен дип, синсез интегеп.
Иң мөкатдәс сүзләремне сөйлим
Фото-сурәтсцә, син күреп.

Әле йөгереп урамнарга чыгам,
Очрашырбыз ксбск ашкынып.
Әле йөгереп кире өйгә кайтам,
Син көтәсең кебек чәй куеп.

Юксынудан җаным телгәләнә...
Бугазымда сагыш төере.
Газапларның иң олысы икән,
Парсыз калган толлар гомере.

Тамчы гөлең, ак яулыгың

Тәрәзә төбемдә тамчы гөл —
Кыңгырау чәчәкләре.
Тамчы гөл коя чәчәген,
Тамгандай күз яшьләре.

Тамчы гөл чәчәге кебек
Ачылдың да... өзелдең.
Сихри, серле, бик кадерле
Гүзәл бер чәчәк идең.

Үзеңне сөям, назлыйм күк
Ак яулыгың сыйпасам.
Тамчы гөлеңне иркәләп,
Кайгы-хәсрәтем басам.

Тамчы гөл чәчәге кебек
Өзелә икән үзәк.
Тик тамырлар өзелмәсен,
Аерылса да куш йөрәк.

Сине юксынудан гөлең
Шиңде чәчәген коеп.
Тамчы гөлең, ак яулыгың
Калды истәлек булып.

Сыкрану

Вакыт — дәва дисәләр дә,
Сагышлар кала икән.
Үткәннәрне сагынулар
Гомергә бара икән.

Үкенеп искә аласың
Ялгышлык-хаталарны.
Бер яхшы сүз җитәр идс
Ямарга яраларны.

Шул тылсымлы яхшы сүзне
Күңелдә саклап йөрдем.
Яшерен яну-көюне —
Егетлек итеп күрдем.

Исән чакта ник әйтмәдем:
«Яратам сине» диеп.
Әрнүле җаным газаплый,
Бәгырьне телем-телеп.

Тик соң инде. Җилләр исте,
Диңгезгә сулар акты.
Мәхәббәткә сусаган җан
Сыкранып күккә ашты.

Җиргә ятып, күккә багып,
Сөеклемә баш орам.
Нәүмиз мәхәббәтем белән
Ялгызым басып торам.

Өмет итәм

«Сиңа дигән гөлләр кочагымда,
Мин бәхетле син янымда чагыңда.
(җыр)

Бүген синең туган көнең
Шатланыр, көләр идең.
Сөйгәннәреңнән сөелсп,
Ләззәттә йөзәр идең.

Дус-туганнар килер иде,
Бүләккә чәчәк тотып.
Балаларың назлар иде,
Үзеңне үбеп-кочып.

Сый-хөрмәт күрсәтер идең,
Өстәлгә куеп барын.
Каберең янында торам,
Җуйгандай аккош парын.

Сиңа дигән чәчәкләрне
Кочагымда иркәлим.
«Урының җәннәттә булсын»,— дип
Изге теләкләр телим.

Әллә ниләр бирер идем
Сине кабат күрергә.
Тәүге ярым, сөйгән затым
Истән чыкмый гомергә.

Сизмәдем китәсеңне...

Көннәр үтте, елың җитте
Гүр иясе булганга.
Торып-торып хәйран калам,
Синсез бер ел торганга.

Иртә киттең Аллаһының
Мәңгелек торагына.
Гомерең көзе кермәде
Әбиләр чуагына.

Камылдан да кыска гомер
Шәм кебек иртә сүнде.
Йөзгәнгә сөю назында,
Сизмәдем китәсеңне...

Бәхет икән бер-береңә
Сөенеч-шатлык илтү.
Үзедер тәмуг газабы —
Саргаеп гомер итү.

Юксыну

«Уңга карасам да юк,
Сулга карасам да юк».
(җыр)

Уңда халык, сулда халык,
Җефетем юк.
Башымны ташка орсам да,
Буласы юк.

Көтмәгәндә, мыштым гына,
Сырхау килде.
Икебезне ике якка
Әҗәл бүлде.

Әйтелмичә татлы, назлы
Сүзләр калды.
Сөю белән мөлдерәмә
Күңел ауды.

Кеше күңелен күрергә
Бер сүз җитә.
Шул тылсымлы сүзне көтеп,
Гомер үтә.

Бергә чакта кирәк икән
Сөйләшергә.
«Син минеке, мин синеке»
Диешергә.

Уй-хисләрне уртаклашмый
Гомер үтте.
Хушлашыр һәм бәхилләшер
Көн дә җитте.

Янәшәмне ямь итәргә
Бәгырем юк.
Исән чакта кешенең ник
Кадере юк?

Үзең йөрәк түрендә

Сиңа карар идем — син юк,
Мәңгегә ташлап киттең.
Гөлләреңне, уларыңны
Үзеңнән мәхрүм иттең.

Кешеләрдәге юксыну
Гөлләргә дә хас икән.
Алар да кайгы, сагыштан
Саргая, сула икән.

Бер ел чәчәк атмый торды
Купшы тамчы гөлләрең.
Үзеңне югалткан кебек,
Югалттым кайберләрен.

Кадерлем ядкарьләре дип,
Гөлләреңә су сибәм.
Үзеңне яраткан кебек
Иркәлим, назлыйм, сөям.

Алар да миңа рәхмәтле:
Һәрвакыт шау чәчәктә.
Үзең шикелле сөйкемле
Тамчы гөлең бигрәк тә.

Дәү чүлмәктәге яраның
Сихри ямьгә уралган.
Әйтерсең, үзең гөл булып,
Чәчәк булып яралган.

Әйтерсең, наз, мәхәббәтең
Гөлләрең булып үскән.
Ягымлы елмаюларың
Шул чәчәкләргә күчкән.

Гөлләреңне төсең итеп,
Саклыйм тәрәз төбендә.
Гөлләрем тәрәз төбендә,
Үзең йөрәк түрендә.

Юк, һаман да ышанасым килми

Юк, һаман да ышанасым килми,
Яшәсәм дә калып ялгызга.
Әйтерсең лә, син күршегә генә
Кергәнсеңдер кебек беразга.

Бәйнә-бәйнә сөйләшербез кебек
Син югында булган хәлләрне.
Бергә-бергә киңәшербез кебек
Яхшы-яман, хәләл-хәрамне.

Җирдә кылган изге гамәлләрне,
Хәбәрләрне килә әйтәсем.
Сөелеп вә сөеп, кабат сине
Уч төбемдә килә йөртәсем.

Юк, һаман да ышанасым килми...
Синең җаның — минем җанымда.
Коръән тотып, Лә Иләһә диеп,
Утырасың кебек алдымда.

Мин йокларга ятсам — син ятасың,
Намазыңа иртүк торасың.
Чәйләр эчкәч, кул аркасы белән
Иренеңне сөртеп куясың.

Шатлыклар да, кайгылар да уртак,
Әйтерсең, син исән бүген дә.
Мәңгелектән хатын, Ана булып,
Елмаясың күңелем күгендә.

Ак яулыгың, хаҗ яулыгың

Көтмәгәндә хушлашты да,
Күкләргә ашты җаның.
Истәлеккә, төсең булып,
Калды ак, хаҗ яулыгың.

Ак яулыгың, хаҗ яулыгың
Сөйкемле үзең сыман.
Үзе нурлы, үзе күркәм,
Ул да бит хаҗда булган.

Ак яулыгың, хаҗ яулыгың
Бөркәнә идең сөеп.
Намаз, гыйбадәткә йөрдең
Арча читеге киеп.

Ак яулыгың, хаҗ яулыгың
Калды чөйдә эленеп.
Көтәр булсаң, янарыңа
Килер идем йөгереп.

Ак яулыгың, хаҗ яулыгы —
Әйләнәсе чәчәкле.
Тик үлсм тудыра икән
Мәңгелек мәхәббәтне.

Юк сыман

Яралардан вакыт дәва, диләр,
Яраларның була, төрлесе.
Мәхәббәтнең кайгы-хәсрәтлесе,
Нур бөркегән кояш төслесе.

Кояш йөзле якты күгебезне
Көзге болыт килеп каплады.
Көзге болыт яшнәп күкрәсә дә,
Зәңгәр күкләр керфек какмады.

Берәүгә дә күрсәтмәсен икән
Тол калуны, Алла каргаган.
Ялгызлыкның рухи-җан газабын
Белә фәкать татып караган.

Яраларым телеп ялкын ялый,
Сагыш ашый яра ярларын.
Ялангач яр кебек җәрәхәтле
Югалткаиар сөйгән ярларын.

Яралардан вакыт дәва, диләр,
Дәвадыр ул, сөю булмаса.
Дәвадыр ул, шул мәцгелек сөю
Хәтер булып янып тормаса.

Сагышлардан ташып китәр булам...
Үткәннәрне үксеп юксынам.
И кадерлем, синсез-мәнсез гомер
Итүемдә мәгънә юк сыман.

Шөкер итәм

Иссеңдәме, иркәм, җырлый идек
«Акчарлаклар», «Рәйхан» көйләрен.
«Әй, гомерем буйларына, Рәйхан,
Оныта алмасам сине, нишләрмен?»

Еллар үтте, картлык килеп җитте,
Инде син дә киттең янымнан.
Ул көннәрнең хатирәсе булып,
Җыр-моң калды гомер юлымнан.

Һава иңләп оча акчарлаклар,
Үзәк өзгеч аваз таратып.
Яра кала икән йөрәгеңдә
Гомер үтсәң, ярың яратып.

Бер канатың сынса, каерылса,
Табып булмый икән ишләрен.
«Әй, гомерем буйларына сине
Оныта алмасам, бәгърем, нишләрмен».

Рәхмәт җырга, моң-сагышка рәхмәт,
Сине хәтерләтеп торганга.
Шөкерана кылам, күңелемдә,
Моң булганга, сагыш булганга.

Алмаш та юк, тиңдәш тә...

«Син ышанма, бәгърем», — дигән шагыйрь,
Вөҗданының әйтеп сафлыгын.
Тик иркәсен, тик бер кадерлесен
Сөя алачагы хаклыгын.

Сине сөеп, яшерен янып-көеп,
Язмыш дигән йомгак сүтелде.
Мәңгелеккә безне ташлап киттең,
Күңелләрнең чите кителде.

Бармы алмаш үткән, сүтелгәнгә,
Тәү хисләргә, ургып ташыган.
Бергә чакның ләззәт кочагында
Мәхәббәтнең тәмен татыган.

Бармы алмаш ир һәм хатын иткән
Зөффаф төндә тойгы-хисләргә,
Нәсел калган бала-оныкларга,
Синең төсләр, минем төсләргә.

Алмаш та юк, тиңдәш тә боларга,
Сыем ялгыз, өем дә ялгыз.
Алмаш-тиңдәш була алмас сиңа
Хәтта җәннәттәге җитмеш кыз.

Җыр — мәрсия

Әҗәл бигрәк иртә килде,
Кадерлемә кул салды.
Шәле кызы — Саниямне
Каерып, тартып алды.

Тартып алды, гүргә салды,
Ялгызымны калдырып.
Кабердәге гөлләре дә
Җаны сыза яндырып.

Көнләштеме әллә язмыш
Тормышлары тигез дип.
Укыласы намазы да
Калды кичен өзелеп.

Күңелкәе йомшак иде
Бәйләгән шәле сыман.
Таң сулары эчә иде
Изгеләр чишмәсеннән.

Йөрим Шәле урамында
Саниямне сагынып.
Алларыма чыкмасмы, дип
Шул шәлкәсн ябынып.

Исраф иттең

Берәм-берәм кеше җиргә килә,
Газап белән туып анадан.
Берәм-берәм җирдән китеп бара,
Әмер булгач, тиңсез Алладан.

Син дә киттең, безне мәхрүм иттең,
Гүр иясе булдың иртәрәк.
Җан җылысы, Ана мәхәббәте
Балаларга иде бик кирәк.

Әйтмәсә дә алар теле белән,
Күзләрендә сагыш, моңсулык.
Оныкларың уйнаган да кебек,
Йөзләрендә юктыр алсулык.

Һәркемнең бар җирдә үз урыны,
Тумыштан ук куйган хак хаклап.
Яшә изге эш-гамәлләр кылып,
Әдәп-әхлак, намус, дин саклап.

Иртә киттең, безне мәхрүм иттең
Исраф иттең тиңсез гомерне.
Денсез юлда йөреп кылганнарга,
Гөнаһларга җәза түгелме?

III



Һәркемнең үз тиңе

Һәрчак тигез бул син...

Ир-егетләр назлап, гыйшык саклап,
Асыл түгәрәгем син, диләр.
Түгәрәген сөсп, яныш-көеп,
Ай-Кояшка аны тиңлиләр.

Түгәрәклек — ул камил төгәллек,
Түгәрәк ич күктә һәр җисем.
Түгәрәктәй камил хатын-кызга
Бик белеп бирелгән бу исем.

Шул камил түгәрәк янында,
Ир-егет бер — алтын багана.
Кушылса, багана — түгәрәк,
Никахлы туй итәр тантана.

Түгәрәксез багана да үксез,
Гомер итүләре күңелсез.
Баганасыз түгәрәк тә көчсез,
Тигез бул син, бул син эчкерсез!

Һәлакәт

Җилләр кубарган дулкыннар
Бер-берен ярга куа.
Азып-тузып искән җилдән
Кимсенгән ятим туа.

Фәхеш ана нарасыен
Чүп савытына аткан.
Шул сабыйны урам эте
Куенына алып яткан.

Үлә ирләр, сына гөлләр,
Хәерче кала илләр.
Әдәп-әхлаксыз кавемгә
Бәрәкәт иңми, диләр...

Белсен!

Илне-җирне иңләп давыл килде,
Кылыч чапты ата-баланы.
Асу-кисү, суеш-үтерештән
Кан туфаны басты калашы.

Яу кырында үлде ил уллары,
Җан, тамырлар шартлап өзелде...
Актарылган тамыр чокырына
Ханлыкларның тәне күмелде.

Варис булып җирдә җаны калды,
Хәтер калды, булып әманәт.
Шәһитләрнең изге ниятенә,
Әманәткә итмик хыянәт.

Канга-кан, үлемгә-үлем — хәтәр,
Афәтле юл, милли фаҗига.
Акыл белән чөйгә суккаласак,
Чәлпәрәмә килер бу ига.

Үз тарихын, нәсел-нәсәпләрен
Яхшы белсен татар баласы.
Алтын Урда, ханлык җирләрендә
Аңа хуҗа булып каласы.

Ишетелә...

Ишегалды иңләп карт әт йөри,
Селәгәе ага теленнән.
Тирә-якка усал аваз сала,
Куркытмакчы булып өненнән.

Көч-куәте бетсә дә, гайрәте,
Усаллыгы әле сакланган.
«Минем токым — соры бүреләр»,— дип,
Күкрәк сугa, була мактанган.

Эт этлеген итә, сырт күпертә,
Өргән була, тешләр ыржайта.
Теш казнасын ләкин корт ашаган,
Ботларына поскан койрык та.

Ныклы адым белән килгәннәрнең
Ишетелә аяк тавышы.
Кояш байый, аның үз капкасы —
Әйләнештә гомер агышы.

Җилләр исә

Җилләр исә, сабый үсә
Әнисе кочагында.
Бәхетле булыр, иншалла
Тәүфыйгы бар чагында!

Җилләр исә, бала үсә,
Хисләре тула, ташый.
Акыллылар акыл белән
Тормышын кора башлый.

Җилләр исә, гомер үтә
Рәхәттә, газапта да.
Үтә читлек эчендә дә,
Хөрлектә азатта да.

Җилләр исә, куәт китә,
Бәхилләшер көн җитә, —
Җилгә очмаган гамәлләр
Озын гомерле итә.

Җилләр исә, җилләр тарый
Картлыкның энҗе башын.
Әманәт булып — безләрдән
Игелек кенә калсын!

Ике куен

Тәүге тапкыр юындыргач ана,
Куенына ала баласын.
Соңгы тапкыр юындыргач бала
Җир куенына сала анасын.

Ике куен. Берсе — юлның башы,
Икенчесе — соңгы ноктасы.
Ике Ананың җылы куенында
Ике дөнья — ишек тоткасы.

* * *

Бер ягында күкнең кара болыт
Тирә-якта яшен уйната.
Бер ягында көләч зәп-зәңгәр күк
Май кояшы нурын тарата.

Йөзек итеп Салават күперен
Нинди көчләр күккә ташлаган...
И-и, сөеклем, шушы могҗизалар
Синең холкыңа бик охшаган.

Бик тә кирәк чак

Көтмәгәндә иртән тугызларда
Килеп керде ике шагыйрь зат.
Икесе дә инде, кызмачалар,
Хәмер даулый болар якалап.

Хәзинәмдә барын мулдан куеп,
Табын әзерләндем аларга.
Берсен-берсе — мактый, мактаныша
Керештеләр тостлар тотарга.

— Син гений,— ди, яше олысына,
— Син дә гений, сәләт иясе.
— Без милләтнең кашка тәкәләре,
Көтү башы килә диясе.

— Ә син, диде, агай миңа төртеп
Гений түгел, аңсыз кибәк баш.
— Ха, ха! Ничек гениально әйттең,
Кибәк кенә түгел, чүбек баш!

Йа, Аллаһым, тәүфыйклы генийлар
Халкыбызга бик тә кирәк чак.
Бирә каһарман асыл ир-егетләр,
Хөр, бәхетле дәүләт төзәчәк!

Табышу

Катнаш гаиләләр ишәя,
Татар читтән кыз ала.
Үзебезнең затлы кызлар
Ят милләтләргә кала.

Болгар, кыпчак булып, татар
Чит-ят канында ята.
Кияү булып, килен булып
Каныбыз кире кайта.

Чит-ят телле булып кайта,
Кан тарта Идел-Йортка.
Таш атканнарга аш атыйк,
Изгелек китмәс юкка.

Сулар кире акмаса да,
Агалар икән каннар.
Нәсел-нәсәбен бер таба,
Адашкан «катнаш каннар».

Кызыл китап

Барысы да бездә урысныкы:
Кышы-җәе, урман, касны,
Елга-күлләр, басып алган җирләр,
Аракысы — алкаш усны.

«Мин урыс»,— ди чегән, кара иегр,
Сыны-бите монгол төслесе.
Тик юк анда Ибен Фадлан күргән
Нәфис буйлы урыс кешесе.

Чит-ят җирләр басып ала-ала,
Урыс үзен, төсен югалткан.
Әйдә, бергә эзлик чын урысны —
Урын бирик Кызыл китаптан.

Сәерләрдән сәер җан

«Русия — щедрая душа».
Телерекламадан

Кемдер «Җаным юмарт, — диеп,
Шапырына, мактана, —
Иркен һәм киң күңелемдә
Хәзинәләр саклана.»

Күкләргә чөеп мактаган
Җанын карадым ачып.
Йа, Хода! Нәрсәләр генә
Ятмый анда укмашып.

Җанның зур бер өлешендә —
Кәһәр, ләгънәт һәм каргыш.
Сыкрана ошбу мескеннәр,
Күреп газаплы тормыш.

Ялган, алдау, урлау-талау
Хәттин вә баштан ашкан.
Бер читтә оят-намусның,
Куркудан коты очкан.

Хыянәт, зина — бер якта,
Хәмер, гайбәт — күршедә.
Яманлык белән явызлык
Көн күрә янәшәдә.

Ике йөзлелек, наданлык
Тау-тау булып өелгән.
Буш вәгъдәләр аунап ята,
Сафсатага төренгән.

Астан уя, өстән юа
Астыртын белән куштан.
Мәкер, хәйлә тозак кора,
Дошман ясыйлар дустан.

Җанда ызгыш, сугыш, талаш,
Гүя мәхшәр бер тоташ.
Һәр тарафта — үлем, кан, яшь.
Әрнү, рәнҗү, ыңгыраш.

...Ә ул җаным иркен, киң, ди,
Тик караңгы ул, кара.
Караңгы кара булганга,
Күренми анда ара.

Бар монда мөселманнарның
Әманәт язмалары.
Яшеренгән татарларның
Бихисап казналары.

Данлы — санлы чын тарихы
Мәгарәләрдә ята.
Ә ул йөзләгән милләтне
Һаман коллыкта тота.

«Өметсез шайтан гына» — ди,
Бу җан акылга килеп,
Бәддогалардан арыныр
Тәүбә-истигъфар кылып...

Җиде күктә

Күп миллион еллар элек, диләр,
Маймыл тәпи йөри башлаган.
Таяк тотып турайган да, имеш,
Мәңгелеккә таба атлаган.

Әлпән-тилпән килеп, китеп барган
Яшәешнең асыл түренә.
Дәверләрнең тирән катламында
Маймылларның эзе күренә.

Бәхәсләшмим, бәлкем, булгандыр да,
Ерак үткәннәрдә бу хәлләр.
Кодрәтле вә тиңсез Хак Тәгалә
Барысын да үзе бәхилләр.

Атам — Адәм, Анам — Хәва (гөнаһ..!)
Тешләгәндә алма җәннәттә,
Таяк тоткан маймыл затларының
Яшәве бар Җирдә, әлбәттә.

Ләкин алар — маймыл булып калган,
Агач башларында бүген дә.
Изге җанлы Адәм балалары —
Аллаһының җиде күгендә...

Эт типкәсе

Иртән чүп-чар өемендә
Сукбай-йолкыш казына —
Кемнәр-ниләр кутан аны
Дөньяның чүп базына?

Эшсез калган, йортсыз калган
Газиз ата баласы.
Нигезеннән аерылган,
Аңа кая барасы?

Алар да кеше. Аналар
Бәхет-тәүфыйк теләгән.
Үсмер исә бу тормышта
Типтерергә теләгән.

...Чит иде бит кәеф-сафа!
Галәмәт иде хәмер!
...Ә хәзер эт типкәсендә,
Чүплектә үтә гомер...

И, үсмер дигән асыл зат!
Акылың белән шәйлә.
Ләззәткә чумсаң муеннан,
Көтә сукбайлык — шәүлә!..

Дөньясы — эт оясы

Хөрәсәнлек кәсеп булды,
Теләнчеләр ил буе.
Күрше йортның чормасында
Бомжларның эт туе.

Табынның хуҗасы — хәмер,
Һәм бәрәңге табада.
Өстәл тирәсе кәефтә,
Урыс дәдәй тамада.

Татар денсезе җыр суза:
«Барганда салыйк әле.
Бу дөньясы — эт оясы,
Типтереп калыйк әле».

Санга бар, исәпкә юк

Кызыл борыннар очрашса —
Бар белгәннәре салу.
Исертә, тилертә торган
Нәмәстә каян алу.

Бөтен хәсрәт, бар хәстәрлек —
Махмыр башны төзәтү.
Одеколон, лосьон ише
«Деликатес» юнәтү.

Сәрхүшләр — ил җилкәсендә,
Санга бар, исәпкә юк.
Баласында һич гаме юк,
Әллә ач ул, әллә тук.

Кара эт бәласе — ак эткә

Кемдер арысланар оясына
Явыз ният белән таш аткан.
Бер ояның чите җимерелгән,
Җәнлек-җанварларны ашаткан.

Арысланнар ярсый, үкерешә
Үч алырга теләп явыздан.
«Бу ак этнең эше булырl» — диләр
Төлке, Бүре дә бер авыздан.

Яннарында соры өтек эт тә
Чәң-чәң килеп өрә ак эткә.
Көндәшенә теше үтмәгәннән
Ул керешкән мәкер, этлеккә.

Бугазына таш органнарның
Утырачак каргыш төере.
Үз канына үзе бер тончыгыр,
Кара, соры этләр өере.

Күке балалары

Һәр тарафтан чит кавемнәр
Агылалар Рәсәйгә.
«Мин урыс» — дип, күкрәк сугa,
Дәгъва кыла илкәйгә.

Тар кысык күзлесе дә,
Киң табак битлесе дә,
Чем кара төслесе дә,
Ал-саргылт йөзлесе дә.

Хәвеф-хәтәр була калса,
Бу күке балалары.
«Чәнчелеп китегез!» — диеп,
Таячак илдән бары.

Тар кысык күзлесе дә,
Киң табак битлесе дә,
Чем кара төслесе дә,
Ал-саргылт йөзлесе дә.

Зәңгәр күзле ил «урысы»
Сыйпый җирән сакалын.
Гомер буе үз урысы
Талый мескеннең малын.

Тар кысык күзлесе дә,
Киң табак битлесе дә,
Чем кара төслесе дә,
Ал-саргылт йөзлесе дә.

«Яңа урыс» дигәне дә,
Ил сатып йөргәне дә,
Погонлы булганы да,
Хакимлек кылганы да...

Бусагада ана...

Бусагада ана басып тора,
Күз төпләре чыккан күгәреп.
Бер җылы сүз ишетергә тели,
Ул сабыен килгән күтәреп.

«Вон отсюда, дрянь-чаплашка!» — дип,
Куа Вася ишек төбеннән.
Акчасы юк. Яшьлеге дә узган,
Мескен башы түбән иелгән.

Борын чөеп, әй, син — гыйбад! — диеп,
Авылдашын куды, хурлады.
Васяларның керде кочагына,
Тәре таккан диеп тормады.

Ә бер көнне әрмән Ованасян
Алып кайтты аны күтәреп...
Валютасы, машинасы булса,
Иблискә дә китте ияреп.

Төннән-төнгә, кулдан-кулга күчеп,
Йөрүләре кәттә тоелды.
Ләззәт тоеп ботын ботка элеп,
Яшьлек укалары коелды.

Бусагада басып тора бүген...
Кочагында — сабый баласы.
Белмим, нинди киңәш бирергә дә,
Кемнән ярдәм сорап барасы?..

Бик күңелсез бер чакта

Мәңгелек йортына күчте
Туганым Рәшит абый.
Хак Тәгалә энҗеләрен
Әҗәл берәмләп саный.

Ире үлгән — ир юньләтә,
Хатынсыз калган — хатын.
Тик алар — тән ямаулыгы,
Түгелләр җанга якын.

Алмаш юк ата-анага,
Бу дөньяга тудырган.
Газиз баласына бөтен
Мәхәббәтен сыйдырган.

Сары яфрак булып калдым,
Килде көзем чуагы.
Аллаһ биргән гомеркәйнең
Күпмесе калган тагы?

Гомер үтте, куәт китте,
Сүнә тормыш учагым.
Гамәл дәфтәрсмне барлап,
Юлга җыенып чагым...

Албасты

Илләдә егылып «уңдык»
Депутатлардан мәгәр.
Юклы-барлы иркенлекне
Тар-мар иттеләр, каһәр.

«Мәскәүле»гә ялагайлар
Зур «тырышлык» күрсәтте.
Мөстәкыйльлек кануннарын
Судка биреп хур итте.

Вертикаль бастырып Мәскәү,
Салды кулларга богау.
Сыртларда аның камчысы,
Ил халкы булды бозау.

Ватандашларына һаман
Албасты булса ватан,-
Булыр алты тиен куян,
Алтыннан артык зыян...

Әти тапкан — мал түгел лә,
Татар малы җәл түгел.

Нәсыйхәт

Йә Хикмәт иясе, җепнең очы
Яшерелгән кая, сер кайда?
Урыс кияү, марҗа киленнәрдән
Татар милләтенә ни файда?

Башын кисте әби-бабасының,
Сыкрандылар үксеп җир-күкләр.
Залим йортларына кияү-килен.
Булып төште кызлар, егетләр.

Үлә-бетә ятны үрчетәләр,
Урыс телле манкорт ишәя.
Дин-имансыз, затсыз бу кавемнән
Кан ташкыны, үлем көчәя.

И, татарым! Уят милли рухың,
Мокыт булма инде бүкадәр.
Син хыянәт итмә әманәткә
Алма каргыш, алма мең кәһәр.

Бер фатирда ике ялгыз

Бер фатирда ике ялгыз тора,
Хисләр сүнгән, күңел сүрелгән.
Икесе дә инде — әби-бабай,
Чырайлары — кара сөрсмнән.

Талпынса да йөрәк тибешләре,
Чын мәхәббәт шытмый бөрешкән.
Кысыр болыт сыман үткән гомер
Үз язмышы белән килешкән.

Берсе — рухи асылына кайткан,
Икенчесе — баккан төрегә.
Бер фатирга ике дөнья сыйган,
Тик сыймаган сөю бирегә.

— Дуңгыз! — дия ире, дер калтырап,
— Чаплашка! — ди аңа марҗасы,
Бәгырьләрдә — үпкә, үкенүләр.
Сыкрандыра йөрәк ярасы.

Бер фатирда ике нәүмиз тора,
Карашлары өтә бер-берен.
Һәр икесе каргый-каргый тели,
Бер-берсенең гүргә керүен.

Сәрхуш

Басып үз гөнаһларына,
Берәү таеп егылган.
Аяк асты — кызыл балчык,
Табадагы май сыман.

Тормак булып тыпырчына.
Тезләнгән, кулын җәеп.
Узган-барган игътибарын
Итмәкче була җәлеп.

Кайсы кызгана мескенне,
Шәфкатьле кулын суза.
Торыр чамасы юклыгын
Белгәч, читләтеп уза.

Соранса да, теләнсә дә
Олы-кечедән хәер,
Эче тулы агу, ялган,
Авызында — «мат», хәмер.

Тормак булып тыпырчына,
Хәрәмләшә, яшь сыга.
Тоткан аны чабуыннан,
Ләгънәт, каргыш, бәддога...

Хикәят

Батып барган күк кояшын урлап,
Хуҗа булмак булган бер дәдәй.
Җәтмә аткан алсу офыкка ул,
Алтын кояш кереп китердәй.

Үз исемен таккан урман, кырлар,
Далаларны, елга, күлләрне,
Дәрьяларга тиң кан, яшь агызып,
Басып алган җирләр, илләрне.

Диңгезләрне, океан суларын
Һәм дә барча биләмәләрен...
Каратмакчы булган тик үзенең
Халкы яши торган җирләрен.

Һәм Кояшны хезмәтчесе итеп,
Өймәк булган эшнең барчасын.
Мич башында ятып, уктан атып,
Кәләш итмәк күлнең бакасын.

Ләкин җәтмә дөрләп янып бетә,
Дәдәй сырхау ала тәненә.
Бу мәкергә бик рәнҗегән кояш
Йөзеп китә Галәм түренә.

Карбыз һәм чикләвек

Ат башы кадәрле карбыз
Күршесе чикләвекне,
Кимсетә, мәсхәрә итә,
Белми чаманы-чикне.

— Торган урның минеке, — ди
Андагы байлыгың да.
Минем ихтыярдан тора
Үзеңнең барлыгың да.

Хөкем инде. Илаһи көч,
Дөньяны селкеп куйды.
Чайкалды карбызның эче,
Тотырык хәлен җуйды.

Кузгалып өслек читенә
Тәгәри китте бер мәл.
Чәлпәрәмә килде төшеп
Каһәр суккан хәрам мал.

Каһәр суккан хәрам мал.
Орлыклар чәчелде. Суы
Ярыкка сеңеп бетте.
Калдыкларын хуҗабикә
Җыеп чүплеккә түкте.

Сикереп төште чикләвек,
Тәгәри иңләп-буйлап.
Иншалла, хәр ил-җирендә
Көнкүрер тамыр җайлап.

— Бер карасаң — чикләвек ул,
Ул да нәкъ кеше кебек.
Кешегә дә ныклык кирәк,
Чикләвек төше кебек...

Бәрелеш

Тыныч кына киң болында йөргән мәлдә
Эләгештe ике тәкә ярсу хәлдә.
Мөгезләре бер-берсенә буталдылар
Шак-шак итеп бәрелгәннән ут алдылар.

Нәр икенең дә теләге — һәлак кылу
Киң болынга тик бер үзе хуҗа булу.
Икссс дә тәҗрибәле — гомер кичкән,
Ошбу җирдә ризык җыйган, суын эчкән.

Сугыш-сөзем килеп җитте шундый хәлгә,
Көтүдәге малкайларга ни эшләргә?!
Бу канлы яман гамәлне барс күзәтте,
Низагны чишү әмәлен, юл күрсәтте.

Әйттеләр барска: «Тәкәләр арып аусын,
Яралардан үз җаннарын тәслим кылсын.
Башкаларга булыр гыйбрәт, булыр сабак,
Җәнлекләргә, үзеңә дә итле табак».

Барс әйтте: «Нәр мәхлүкнең үз бәһасе,
Азык түгел сасы тәкә үләксәсе».

Хуҗа булып китмәкче

Кара кош җәйгән канатын,
Кояш нурын каплаган.
Илдә сугыш, көндә суеш,
Юк урын, кан акмаган.

Урыс агай Җирне-Күкне
Үзенеке итмәкче.
Җае чыкса, бар җиһанга
Хуҗа булып китмәкче.

Хуҗа булмакчы Галәмгә,
Кояшка, тамга сугып.
Җилне дә бирик урыска
Йөрсен кырда җил куып.

Афәт

Ут өстендә кызган табадагы
Борчаклардай шартлый йорт-җирләр.
Үч өстендә торган ил өстендә
Ыгы-зыгы ут төртүчеләр.

Хур-мәсхәрә күргән халыкларның
Ядрә булып ява ләгънәте.
Бомба булып шартлый илбасарда
Гасырларның зары, нәфрәте.

Ил өстендә каргыш, кан, ыңгыраш...
Гөнаһсызның үлем газабы.
Афәт-хәсрәт биргән сугышларның,
Сәясәтнең бармы азагы?

Ут өстендә кызган зур табада
Шарт-шорт итеп мылтык, туп ата.
Явызлыклар кылган ил эчендә
Бер-бер артлы ауган йорт ята.

Троллейбуста

Троллейбуста әби басып бара,
Таяк тоткан хәлсез куллары.
Урындыкта — типсә тимер өзәр,
Килен кызлар, онык-уллары.

Мескен карчык чүгеп-түнеп китә,
Аякларның беткән егәре.
Көч-куәтсез калган ябык иңнәр,
Ил күтәреп торган элгәре.

«Юл газабы — гүр газабы», — диләр,
Йомычкадай әби чайкала.
Дулкын аткан диңгез чүп-чары да,
Яр буенда кибеп, югала.

Троллейбуста әби басып бара,
Өс-башында — кемнән калганы?
Бауы тузган иске сумкасында,
Ипи дә сөт — илдән алганы.

Нинаять

Нинаять, татар уянды,
Зур итеп ачты күзен.
Коты очты ул бүгенге
Күреп үзенең йөзен.

Дәүләт киткән, ирек беткән,
Ил төбәк булып йөри,
Табышның җитмеш өлешен
Мәскәүгә ясак түли.

Ас-өсте җир байлыгына,
Милеккә үзәк хуҗа.
Халык мәхшәрдә интегә,
Карт-коры күрә нужа.

Мәкер-хәйләләрен корып,
Мәскәү хөрлекне буа.
Манкортлашкан мөртәт татар
Хуплап кул чабып тора.

Динсез калган, юлдан язган,
Намус, ояты качкан.
Күмәкләшеп әчә татар
Хәмергә киң юл ачкан.

Ата улга үрнәк түгел,
Ана — кызына абруй.
Һәркемнең кулында шешә,
Көн дә бәйрәм, көн дә туй.

Хәмер дигән җен-аҗдаһа,
Газраилдән дә узып,
Яшен-картын йота бара,
Йөрсә ул азып-тузып.

Рәсәй буйлап маржа коча
Мөртәт татар ирләре.
Татар хатыны куенында
Чит милләтнең төрләре.

Агачлардан агач үсә,
Чирәмнән чирәм үсә.
Укыш-мукыш гаиләдә
Кыйбласыз бала үсә.

Туган теле дә юк аның,
Анасы ярты-йорты.
Юк ата тәрбиясе дә,
Атасы каты-коты.

Үсә бала әби-баба,
Гореф-гадәтен белми,
Тәртип-тәрбиясез генә,
Әхлак-әдәпләр күрми.

Кулында сыра шешәсе,
Авызында тәмәке.
Ике сүзнең берсендә мат,
Ул имансыз, әшәкс.

Кайсы энәдә «утыра»,
Кайсында яман СПИД.
Бу кыйбласын җуйганнарга
Алланың каһәре бит.

И, татарым, акылга кил,
Милли аңыңны уят.
Куәт-гайрәтеңне туплап,
Динеңә, үзеңә кайт!

Дөньяны иңләп ураган
Мәшһүр татар уянды.
Акыл белән гамәл кылып,
Дәүләт корасы калды.

Татар таеп егылмас

Хаҗәт үтәргә койрыгын
Күтәргән булган сарык.
Шуны гаеплән кәҗәләр
Көләләр шарык-шорык.

И, милләттәш, булма кәҗә,
Үзеңнән үзең көлмә.
Ялангач артың күрсәтеп,
Илне мыскыллап йөрмә.

Без дистә мең ел борынгы
Мәшһүр төрки кабилә.
Бер милләттән дә ким түгел,
Җиз иләктән хет илә.

Гарьләнмә татарлыгыңнан,
Телеңне дә яшермә.
Татар теле җир-әнкәдәй
Туган мәңге яшәргә.

Таш ярылмый, баш ярыла
Башны ташка органнан.
Чын татар таеп егылмас,
Яла ягып торганнан.

Сандугач нәни булса да,
Әсирли сихри моңы.
Сандугач булып сайрашыйк,
Татарның атты таңы.

Бердәмлектә — көч, бәрәкәт,
Таркаулыкта — һәлакәт.
Үз милләтең белән тату
Итеп яшәүдә хикмәт.

Мөселманнар, берләшегез!

Мөселманнар, берләшегез!
Сынау сәгате сукты.
Илебезне, динебезне
Аллаһ сакларга кушты.

Мөселманнар, берләшегез!
Тәре коллары килә.
Кардәшләрне юк итәргә,
Илләрне туный, телә.

Мөселманнар, берләшегез!
Террорны сылтау итеп,
Бетермәк алар Исламны
Дәһшәтле утта өтеп.

Мөселманнар, берләшегез!
Бу — Ходайның әмере.
Нефть өчен ябырылды
Илбасарлар өере.

Мөселманнар, берләшегез!
Ниятебез мөкатдәс.
Коръән-Кәримле өммәтне
Аллаһ үзе таныламас!

* * *

Ап-ак чәчәк атты бадьян[1],
Тәмле хуш ис таралды.
Асыл тәлгәшләрне күрсәп,
Гөл-чәчәкләр таң калды.

Масаймады күпшы бадьян,
Чөймәде борынын өскә.
Яшьнәде багышлап үзен
Дөньяви күркәм әшкә.

Беркөн балта-пычкы тотып
Килделәр явыз затлар.
Тырпаеп калды ботаклар,
Гөлләрне изде ятлар.

Җир-Ана таптап таланды,
Дөньяның яме бетте.
Кан-яшь тулы нәүмиз яктан
Сайрар кошлары китте.

[1] Бадьян — сирень, әрлегән

Үзәге нык торганнарны
Булмый йолкып, корытып.
Сынган, киселгән агачлар
Тамыр җәйдә ныгытып.

Җир-Анабыз тылсымлы су —
Зәмзәм бирсә эчерде.
Балкыды сирень ямьлерәк,
Күкләр аңа көч бирде.

Язгы хисләр

Белмим инде нишләргә дә,
Кайсын гына сөяргә?
Кайсын күкрәгемә кысып:
«Бердәнберем», — дияргә.

Ничек димен бу кызларны
Элек күрмәдем икән?
Әллә гөл-чәчәкләр белән
Шытып чыктылар микән?

Әллә инде яз аларны
Үз яменә бизәгән?
Әйтерсең, гүзәл чәчкәләр
Төсен бергә бәйләгән.

Сихри көчләр яшеренгән
Нур балкый йөзләрендә.
Бер чибәркәй өчен генә
Урын бар йөрәгемдә.

Язгы хисләр, шашкын хисләр,
Гөрләвек, ташкын хисләр,
Гашыйклар ләззәттә йөзә,
Иркәли ямьле төсләр.

Һәркемнең үз тиңе

Офыкларга нурлар бөркеп,
Язгы сихри таң ата.
Әйтерсең күкнең читендә
Иркәм елмаеп ята.

Минем иркәм үзе күркәм,
Карашлары ягымлы.
Мәхәббәте йөрәгемә
Бал-май булып ягылды.

Баллы-майлы җаным эри,
Күңел җылысын тоеп.
Шадра да йөрәк яндыра,
Яшәсәң яна белеп.

Һәркемнең үз тиңе була,
Була йөрәк ачкычы.
Кемгә балан да шикәр-бал,
Кемгә җиләк тә ачы.

Хак Тәгалә җан иясен
Парлы итеп яраткан.
Сөю серләрен яшереп,
Күңел түренә япкан.

Чәчәк атыр

Урысның бар өч батыры:
Башлык булыр Муромецы...
Татарның халыкны еккан
Өч аяк чалучысы:

Мин-минлек, көнләү, хөсетлек...
Бәрелтерә татарны...
Ләкин күпме көрәшеп тә,
Җиңеп булмый аларны.

Бәрәкалла, булды дисәң,
Янә ул өстен чыга...
Аяк чалып, хәрәм салып,
Татарын бәреп ега.

Ята татар һушы китеп,
Хәл җыеп, күккә карап.
Гыйбрәт алып җай таныса,
Татарның эше харап.

Милләттәшләр! Мин-минлекне,
Көнләшү, хөсетлекне,
Көчне көрәшкә юнәлтик,
Саклыйк мөстәкыйльлекне!

Дастан батырлары кебек
Тәвәккәл, кыю булыйк.
Бер җан, бер тән күк берләшеп,
Эш-гамәлгә тотыныйк.

Таңнары атар — татарның
Кояшы чыгып балкыр.
Каһарман уллары белән
Милләт тә чәчәк атыр!

Кочты

Итәге чак күтәрелсә,
Гөлт итә иде йөрәк.
Хәзер гаурәтен каплаган
Чын асыл затлар сирәк.

Серле җирләре ачылды,
Сихрилек җилгә очты.
Азгын сөйкемсез сөякне
Иблис токымы кочты.

Ил-җир — утлы табада

Кемнең туган көне икән?
Әллә изге бәйрәм көн?
Бар да салмыш, йөри чалыш,
Спонсоры икән кем?

Берәвесе лыкын булган,
Чүплеккә барып түнгән.
Бер Сәрхүше балконыннан
Егылып төшеп үлгән.

Поминка мәҗлесе шат,
Табында сый өеме.
Фатирын сатып типтерә
Бомж, сукбай өере.

«Дөнья малы — дуңгыз каны,
Бүген бар — иртәгә юк.
Хәмер елга булып аксын,
Тик ятып та тамак тук».

Уен-көлке, җыр да бию,
— Тост! — ди, сәрхүш томада.
Ямаулы язмышлар яна,
Ил-җир утлы табада.

Белеп тор!

Булып скиф, булып хазар һәм булып һун,
Әби-бабам ил-җир иңләп күргәннәр көн.

Без борынгы алан, пәчәнәк, сармат та,
Һәр төрки кавемдә каныбыз акмакта.

Мең-мең еллар дала балкып чәчәк аткан,
Шул далада төрки бабам ат уйнаткан.

Чал тарихта мәгълүм мәшһүр исемнәре,
Һәм үзгәрми калган төрки җисемнәре.

Халкыбызга тәңгәл ислам динен алдык,
Ассалар да, киссәләр дә исән калдык.

Соңгарак без болгар, кыпчак дип аталган,
Варислары булып җирдә татар калган.

Сакланалар төрки геннар безнең канда,
Без зур халык, без бер төрле, без күп санда.

Мишәр, типтәр, мажгар, нугайбәк, керәшен,
Себер, кырым татары диләр, бер ишен.

Аллаһ безне җир йөзенә мулдан чәчте,
Кыйтгаларны урап татар гомер кичте.

Днестр, Иртеш, Кырым, Балхан җирләре,
Идел-Урал — татарларның үз илләре!

Ул җирләрдә түтел без килмешәк, диаспор,
Борынгыдан ул безнең җир, син белеп тор!

IV



Йә, әйт, кеше!..

Ташлар сере

Көрәк очыннан очып китте чуер таш,
Бәрелештеләр ак таш белән башка-баш.

«Чок!» иткән аваздан сискәнеп киттеләр,
Үзләрен бер-берсенә таныш иттеләр.

Хикәя кылды чуер таш: «Биш йөзләп ел
Зикер иттем җир астында, чыктым быел.

Нигезендә яттым ханыбыз сарае,
Кол Шәриф мәчетендә шуның бер ае.

Кардәш-ыруг сөякләре күп ятмакта,
Оныкларга риза-бәхилләр булмакта.

Бирәләр изге гамәлләргә фатыйха,
Кылсыннар рухларыбызга хәер-дога.

Варисларыбыз яуласын чын азатлык,
Ил-җиребездә кол булып озак яттык.

Татарларга берләшергә кирәк күптән,
Мөстәкыйль булып яшәүнең чоры җиткән.

Мин — чуер таш, нык, чыдам таш, чакма түгел,
Ут чыгарырга өндәмим, ният изгел.

Ак ташларны, якташларны бергә туплап,
Дәүләт төзик, телне, динне калыйк саклап»...

Ак таш шунда нык тетрәнеп телгә килде,
Чуер ташның хак-хакыйкать сүзен бүлде.

Сөйләп китте үз башыннан үткәннәрен,
Белгәннәрен, нинди язмыш кичкәннәрен.

«Шан дәүләтне бүлгәләдек ханлыкларга,
Ирек бирәбез, имештер, халыкларга.

Аерылган вак ханлыклар көчсез калды,
Үзара ызгыш-талаштан сүнә барды.

«Аерылганны — ак, бүленгәнне — бүре
Ашар» ачысын татыйбыз шуннан бирле.

Хаталардан бәхетсезлеккә тарыдык,
Сусыз калган мичкә шикелле таралдык.

Бастык ата-бабалар баскан тырмага:
Керешеп һәрбер кавем дәүләт кормага.

Явыз дошманнар яу чапты уңнан-сулдан —
Кыбырсынып, таркалуны көткән булган.

Ябырылды ханлыкларга берәм-берәм,
Суйды-кырды халыкларны дәһшәт белән.

Яшьүсмерләр каны акты елга тулып,
Башлар очты, калды милләт өнсез булып.

Кәһарманнар яу кырында баш салдылар,
Карт-карчыкны корбаннар кебек чалдылар.

Хатын-кызны, балаларны кол иттеләр,
Ә бер ишләр ирексездән тәре үптеләр.

Идел-Чулман дәрья булып кан-яшь акты.
Гаярь ирләр ирек даулап яуга чыкты.

Бетте Урда, аннан ханлыклар таркалды,
Китте хөрлек, ил сатылды, дин сатылды.

Сыкрана ошбу афәтләрдән Җир-Ана,
Кайгы-хәсрәттән әле дә утта яна.

Әйтә: «Бәддогам илбасар улларыңа,
Кара язмыш ятсын барыр юлларыңа.

Күрмә син, җыйган малыңның бәрәкәтен,
Гауга тынмасын илендә ут һәм төтен».

II

Бу каргышларга күкләр дә «Амин», диде, —
Фәрештәләр Аллаһ каршысына килде.

Диделәр: «Әйт, тиңсез көч-кодрәт иясе,
Сөекле өммәтеңә бу ни бәласе?»

Диде Аллаһ: «Аларга Коръән индердем,
Кануннарын үтәп пәп яшәгез,— дидем. —

Мөселман кардәшен, берүк, рәнҗетмәсен,
Аны саклап, аны яклап җанын бирсен.

Арканыма нык тотынса ошбу милләт,
Рәхмәт-шәфкатем ирешер, булып хөрмәт.

Ислам диненә иман китергән халык,
Алыр беркөн хөррият һәм хәләл байлык.

Бу фаҗига алар өчен сынау иде,
Гөнаһ-хаталар җәзасын күрсен инде».

Явыз патша кат-кат яман фәрман бирде,
Шәһәр, авыл, җиребезгә дошман керде.

Күплəп алар яшен-картын чукындырды,
Чукынмаган инсаннарны су тындырды.

Хак мөселман ил, диненə тугры калды.
Куе урманнарга качып, сихəт алды.

Керəшеннəр җир-суларга хуҗа булды,
Тик исем һəм җисеменнəн мəхрүм калды.

Алар бүген дə торалар аваз салып,
Шан милләтебез тəнендə яра булып.

Шул ярадан əби-бабам каны саркый, —
Алар динен сатканнарга лəгънəт укый.

Илен саткан, динен саткан — үзен саткан,
Сатлык җан дигəн хурлыкта гүргə яткан.

Ятлар җиренə күмелə агач табут.
Өч аршин җир һəркемгə була табып.

Сатлык җанга байлыгын бирсə дə дошман,
Үз иленда түгелдер ул хəтта олтан.

Килмешəк ул анда, бай булып калса да,
Мал-мөлкəтлəр, исем, дəрəҗə алса да.

«Поганный татар» хəзер дə безнең исем, —
Икенче сорт халык итеп тотар өчен.

Дүрт йөз илле ел ятка хезмəт кылабыз,
Бетеп бара гореф-гадəт, дин-йолабыз.

Илбасарның эте-бете безне изə,
Шул золымга, мəсхəрəгə халык түзə.

Көн күрəбез илбасар-залимга ярап,
Хөрмəткə лаек түгел без аңа карап.

Илсез калдык, җирсез калдык, телсез калдык,
Дошманнарның дəвамына җирлек салдык.

Ятлар белəн катнаш гаилəлəр корабыз,
Ə үзебез чүлдəге гөлдəй корыйбыз:

Катнашларда[1] урыс телле бала үсə,
Денсез татар үз тамырын үзе кисə.

[1] Катнаш — буйдыр, өметсез

Хөсетлек тә, көнчелек тә, мин-минлек тә
Татар белән яши бирә иминлектә.

Татар башын татар ашый элек кебек,
Бер-берсенә аяк чала әләк түгеп.

Оешмалар, гаярь ирләр таратылды,
Кем кыйналды, кем илеңнән озатылды.

Өстәгеләр алдап, талап байлык җыя,
Мескен халык үлемтек акчасын җуя.

Түрә үзгә, дингә үзгә, халык үзгә,
Бу өчлекнең берләшүе кирәк безгә.

Кул кушырын карап тору — зур җинаять,
Ирек өчен көрәшергә тор, җәмәгать!

Үткәннәрдән нәтиҗәле сабак алыйк,
Нык ташлардан ышанычлы нигез салыйк.

Һәйкәл булып күккә ашыйк Казансуда,
Шәһит киткән каһарманнар булсын сында.

Балкып торыр ул изге җаннарның нуры,
Халкыбызның юлы һәрчак булыр туры.

Һәйкәл белән Сөембикә манарасын,
Салават күпере кочар ике арасын.

Кояшлан нур, айдан алырбыз яктылык,
Балкырбыз ак һәм чуер таш якташ булып.

Туплау-барлау кирәк сибелгән татарны,
Бер учка җыю зарури без — таркауны.

Халкыбызның көч-куәте — бетмәс дәрья,
Тик оешканлык, бердәмлек җитми аңа.

Ақыл-акылы, дәрт-дәрманы хәттин ашкан,
Ләкин динсез, телсез калып, ул адашкан.

Милли аң күк асыл сыйфат кире кайтсын,
Үз илендә татар бәхет-тәүфыйк тапсын!

Булмасын яман гадәтләр йортыбызда,
Калсын алар гыйбрәт булып артыбызда.

Хөсетлек, көнчелек чире кимермәсен,
Йортыбызны ызгыш-талаш җимермәсен.

Милләт көче, киләчәгә бердәмлектә,
Дин гыйлемен, фән гыйлемен белгәнлектә.

Халкыбызга әдәп-әхлак, гореф-гадәт,
Мәдәният, әдәбият итсен хезмәт.

Мәгърифәт ислам диненә сугарылсын,
Изге Коръән кануннары хөкем кылсын.

Кирәкмәстер чит дәүләтнең законнары,
Үзебезнең милли дәүләт кирәк бары.

Шартнамәләр төзеп хәер сорамыйбыз,
Тик мөстәкыйль булсын Идел-Уралыбыз!

Мәңге яшәп, ул кояш кебек балкысын,
Башка милләтләр дә шатлык, бәхет тапсын.

Йа, чуер таш! Тәкъбир әйтеп чыгыйк юлга,
Милләттәшләрнең тоташсын кулы кулга!!!

Йә, әйт, Кеше!

Алдау, ялган, хәйлә, хыянәт һәм...
Абау ямьсез букет, син, Кешем.
Котсыз әхлак, гадәт, сыйфатларга
Уралырга кайчан җитештең?

Ә бит үзең — гүзәлләрдән гүзәл,
Аллаһ могҗизасы син — Адәм.
Аның тиңсез иҗат көч-кодрәте,
Үзең-җанлы гаҗәп бер Галәм.

Елмайганда йөзең нуры белән
Кояш кына бәлкем, тиңләшә.
Балкып торган серле күзләреңнән
Йолдызлар да хәтта көнләшә.

Бер карасаң- тәүфыйк, итагатьле,
Фәрештәләр кебек изге җан.
Бер карасаң — синең вәхишлектән
Асты өскә килә бу җиһан.

Бер карасаң — аңлы, акыллы зат,
Игелекле гадел, дус, иптәш.
Бер карасаң, син ерткычтан-ерткыч,
Юлларыңда үлем, канлы яшь.

Синең кыргыйлыктан, җаһиллектән
Җирләр, күкләр ярсып тетрәнә.
Шартлаулардан атом дәһшәтенең
Урман, кырлар чүлгә әйләнә.

Явызлыгың, усаллыгың белән
Тиңләшә алмый бер җан иясе.
Үзен аскан, суйган, золым кылган
Ул син — кеше — үлем шәүләсе.

Үз баланны табып багар өчен
Никадәр көч сарыф итәсең.
Үсеп буйга җиткән газизеңне
Бер мизгелдә юк та итәсең.

Йә, әйт, гүзәл, аңлы, акыллы зат!
Яшәвеңнең нидә мәгънәсе?
Кеше булып, җиргә килгән көннән
Кан түгәсең, Алла бәндәсе.

Адәм улы Һабил үтерелгәч,
Җиде кат күк әрнеп елады.
Фаҗигане белеп, фәрештәләр
Аллаһыга сыкрап сүз салды:

«Җир өстендә хәлифәмсе булыр
Кан коючы Адәм баласы?»
«Шул Адәмгә һәр җан иясенә
Боерылды сәҗдә кыласы»... —

Булды җаваң, Яшен ялкыннары
Ялт-йолт килеп, дөнья айкады.
Нәфрәтләнеп Илаһи көч җирне
Галәм дәрьясында чайкады.

Туфан купты, тузан өермәсе
Бөтерелеп ашты күкләргә.
Бәндәләрен ут, су белән Аллаһ
Һәлак итте: гыйбрәт күпләргә.

II

Дөньядагы аңсыз җан иясе
Җан асрар өчен җан кыя.
Зиһен-аңга ия Кеше заты
Кеше җаныш кыеп мал җыя.

Мин акыллы, диеп масаясың,
Үз-үзеңә әле бер кара!
Нәфсең үткән юлда — хәрабәләр,
Корбан кала, хәсрәт, кан кала.

Кан-яшь түгел, байлык туплау өчен
Сугышасыз һаман үзара.
Тамаклары туйгач, ерткычлар да
Башкаларга өлеш чыгара.

Сиңа, Кешем, Шәфкать-мәрхәмәтле
Миһербанлы булу тиешле.
Тиеш булмаганны аласың син,
Умырасың алтын-көмешне.

Сый-хөрмәтен мулдан биргән Җирне,
Табигатьне көн-төн талыйсың.
Җир астында яткан байлыкларны,
Үзеңнеке итеп саныйсың.

Мөлкәтеңнең исәп-хисабы юк,
Җиде буыннарга җитәрлек,
Подвалларда яшерелгән алтын
Үзеңне дә күмеп китәрлек.

Үзең туйсаң, күзең туймый һаман,
Туплаганың һаман аз сыман.
Акыллымы, әйтик, кесәсенә
Миллионнарча хәрам мал җыйган?

Алтын-көмеш, энҗе, асыл ташлар
Затлы ташлар, ләкин аш түгел.
Кешелекнең иң күп өлешенең
Өлеше юк, алар ач бүген.

Алдап-талап җыйган кеше хакы
Күңелләрдә нәфрәт уята.
Һәм кешеләр, үз хакларын даулап,
Сезнең ишеләргә ут ата.

Тик берәү дә үзе белән алмый,
Җир өстендә кала байлыгы.
Гүр иясе булган бәндәләрнең
Бар байлыгы — тик баш казыгы.

Ахирәттә исәп-хисапларга
Кылган эш-гамәлең алыныр.
Мизаннарның бер ягына — сабап,
Бер ягына гөнаһ салыныр.

III

Түрәләрнең мәнфәгатен яклап
Күпме асыл ирләр үлмәгән?
Дошман диеп, каршы якка ата,
Берсен-берсе һич тә белмәгән.

Ә зиннәтле мәрмәр сарайларда
Зур түрәләр табыш бүлешә.
Хәләл көчен куеп, тир түккәнгә
Исем бирә, медаль өләшә.

Кеше хакын урлап баеганның
Ояты юк, күзен кан баскан.
Нәфесләрен тыя алмаганнар
Намусларын саткан, югалткан.

Ләкин бай да, ярлы-ябагай да
Ахыр чиктә — тик гүр иясе.
Анда синең малың, даның да юк,
Иң кыйммәте — гамәл бәясе.

IV

Йә әйт, Кеше! Җирдә хәким булып,
Бармы чыплап рәхәт күргәнең?
Таныйсыңмы фарыз гамәлләрне,
Кануннарын изге Коръәннең?!

Нинди мирас җирдә калдырасың?
Кылган эшең нидән гыйбарәт?
Тамчылардан күл җыела. Тамчың
Китерәме илгә бәракәт?

Утырттыңмы бакча, салдыңмы йорт?
Инсафлымы, Кешем, дәвамчың?
Үтисеңме Аллаһ кушканны син,
Саф вә изгеме соң иманың?

Никахлашкан асыл ярың белән
Күркәм, тату гаилә кордыңмы?
Сиңа ризык, яшәү биргән затка
Рузә тоттың, намаз кылдыңмы?

Яхшы кеше булу авыр шөгыль,
Игелекле булу — тагын да.
Кеше бәхет таба, мәхәббәте,
Иман торса күңел сагында.

Ацла, кешем, минем бу сүзләрем
Нәсыйхәт тә түгел, үгет тә, —
Гөнаһлардан арына алмассың син,
Соң көнеңдә Коръән үбеп тә...

Без, гөнаһсыз сабый бала булып,
Шыр ялангач Җиргә киләбез.
Яхшы, яман юлны үтәбез дә,
Көфенлектән гүргә керәбез...

Иң югары бәһа

I

Тәүге тапкыр Биләр мәчетендә
Аллаһ сүзен бабам ишеткән.
Кодрәтле һәм күркәм ул авазны
Күңеленә алып эш иткән.

Илаһи нур иңгән җан-тәнснә,
Йөзләренә — иман балкышы.
Аллаһыдан иңгән хакыйкатьне,
Изге иткән Коръән яктысы.

Игелек кылу, изге бу гамәлләр,
Алып килгән бәхет ил-җиргә.
Әдәп-әхлак, тәртип һәм тәрбия
Бала-чага, хатын һәм иргә.

Болгар даны ерак илләрдә дә
Иң югары алган бәһане.
Кәрваннарны Идел буйларына
Җәлеп иткән Коръән әһәце.

Далаларны иңләп яңгыраган
Мәзиннәренең моңлы азаны.
Ахыргача хак мөселман булып,
Яшәү бсзгә Аллаһ язганы!

Аллаһының нуры, иман нуры,
Коръән нуры татар йөзендә.
Үз кадерен, дан-шөһрәтен белгән —
Татарлыгын саклый үзендә.

Ул һәрвакыт горур һәм тәвәккәл,
Кыю атлый хөрлек юлыннан.
Бил алыша көрәш мәйданында
Чыгар өчен коллык чорыннан.

Ул — фидакарь, ул — каһарман татар,
Мал-байлыкка сатмый намусын.
Нәфес колы, корсак колы түгел,
Дәвалаучы милләт ярасын.

Мнһербанлык ана сөте белән
Гадәтенә кергән сабыйдан.
Хәләл көчен түгеп тормыш итә
Үрнәк алмый «өлкән абыйдан».

Ул хезмәттә тырыш, булсын диеп,
Җаен белеп эшли һәр эшен.
Һәр нәрсәгә кулы ятып тора,
Һәр тарафта таба үз ишен.

Тик гыйбадәт кылып яшәгәннең
Бәрәкәтле булыр дәвамы, —
Аллаһының кушканнарын үтәп,
Милләтснә табар дәваны.

Иман нуры, Ислам, Ихсан нуры
Көч-куәт, дәрт бирә татарга.
Шәригатынең изге кануннарын
Фарыз иткән безгә тотарга.

Коръән-хәдисләрдән белем алып,
Яшәү, эшләү безне коткарды.
Бары Коръән аша хакыйкатьтән
Аерырга мөмкин юк-барны.

Коръән хөкемнәре һич өзелмәс,
Аллаһ безгә биргән аркандыр.
Барсак тотып ошбу аркан очын
Бәхетле һәм якты юл булыр.

Шушы хакыйкатьне яхшы белгән
Безнең дини әби-бабалар.
Һәм бүген дә асыл варислары
Кыйблабызны саклап баралар.

II

И, татарым! Буыннардан килгән
Әманәткә итмә хыянәт!
Намаз һәм дә барча гамәлләрең
Аллаһыга булсын гыйбадәт!

«Изге Коръән кеше ахирәткә
Әзерләнсен өчен бирелде.

Аның белән гамәл кылганнарга —
Фирдәвес җәннәт», дислдс.

Идерелдс Коръән терсләргә,
Ул — мөэмин-мөселман кануны.
Яшә, кыл гыйбадәтләр Коръәнчә
Булырсың Аллаһның якыны.

Коръәндәге сүрә, аятьләрне
Адәми зат алмас үзгәртә.
Төп китапта язган, саналганнар
Кыяметкәчә калыр үзәктә.

«Әйт, — дидс — Аллаһ, изге Коръәнне
Мөхәммәт чыгарган димәсен.
Әгәр ышанмый икән берәрсе.
Берәр яңа сүрә китерсен».

Тик кяферләр Аллаһ сүрәсенә
Көлимә сүз өсти алмады.
Ләкин Инҗилне алар үзгәртеп,
Нәсарый диннәре ясады.

«Мөселманнар, сез — Ислам милләте!
Бүленмәгез төрле юл китеп.
Курыкма син изге ахирәттән,
Ал мәңгелек аны йорт итеп.

Аллаһының дусты булып яшәү —
Мөэмин-мөселманга бәрәкәт.
Намаз — иң зур Аллаһ зекерсдер,
Иманлы бул, кыл син гыйбадәт.

Намаз — диннең йөрәге һәм башы,
Намаз кылган нурлы булырлар.
Барлык мәхлукъ бер Аллаһка гына
Иманланыш сәҗдә кылырлар.

Юк булсын монафыйк! Баш тартса ул
Чын мөселман булам диюдән.
Булырсың үзең дә син монафыйкъ
Кяфер белән дус-иш йөрүдән.

Катнаш гаиләләрдә туган бала
Ике диннән мәхрүм җан-шытым.
Иман белән гамәл, җан белән тән —
Алар икәү генә бербөтен.

Динсез милләт — мал-мөлкәтсез келәт,
Әдәп-әхлаклы да булалмый.
Динсез гаилә, динсез тәрбия дә
Асыл затлы нәсел биралмый.

И, татарым! Бөек, Һун токымы!
Ким-хур булуларың бик җиткән.
Кяферләрне Аллаһ ләгънәт итте,
Сатлык җандыр аны дус иткән.

III

Йә, Аллаһым, «Бул!» дидең дә, мине
Кызыл балчыгыңнан яраттың.
Җир-Ананың гүзәллеген күреп,
Гашыйк булдым аңа, яраттым!

Йә, Аллаһым, бар һәм барлегеңне
Таныр өчен Күккә караттың.
Дөньяңның мин камил төзелешен,
Төгәллеген күреп шаккаттым.

Йә, Аллаһым, Кодрәтеңне күрдем,
Акыл җыйдым, каран йолдызга, —
Җирдә үскән һәрбер үсемлегең, —
Кеше аңы җитмәс могҗиза.

Йә, Аллаһым, мең-мең рәхмәт Сиңа
Хис, мәхәббәт, сөю биргәнгә.
Гаилә корып, сөеп һәм сөелеп,
Бу дөньядда яшәү күргәнгә.

Йә, Аллаһым, эш һәм гамәл бирдең,
«Яхшылык ит! — диеп, Кешегә.
Изге ният белән кылганнарың
Игелек булып кайтыр үзеңә».

Йә, Аллаһым, биреп күрсәтмәләр,
Канун китаплары индердең.

Гыйбадәтләр кылыр, сөйләр өчен
Һәр кавемгә сөйкем тел бирдең.

Йә, Аллаһым, Адәмеңне сөеп,
Зиһен бирдең аңа, аң-белем.
Җәннәт ишекләрен ачар өчен
Изге китап — Коръән индердең.

Йә, Аллаһым, шул китабың ача
Икс дөньяцның да ишеген.
Һәрбер сүрә, аять, догаларың
Юлламасы җәннәт иленең.

Йә, Аллаһым, һәр эш-гамәлемә
Бисмилламны әйтеп керешәм.
Көч-кодрәтле бер Илаһым, Сиңа
Гыйбәдәтләр кылып баш иям.

Дөньялыкта белеп, белми кылган
Хата-гөнаһларым ярлыка.
Ышанамын үлеп тереләсенә,
Җәннәт, тәмугларың барлыкка.

Иксез-чиксез Галәм киңлегендә
Мәхшәр көне булыр, суд көне.
Бер-бер артлы үтәр күз алдыннан
Һәр адәмнең тормыш иткәне.

Ришвәт биреп, сыйлап, майлап-җайлап,
Котыла алмас аннан берәү дә.
Хөкем кырыс булыр, ләкин дөрес,
Яхшы-яман ятар үлчәүдә.

Мәңгелек һәм мизгел — ике дөнья,
Акыл биргән Аллаһ аңларга.
Уңда аклык, сулда кер, бозыклык,
Ике юлның берсен сайларга.

И, син, бәндә, Аллаһ кушканнарны,
Кануннарын үтәү фарыздыр.
Коръән-Кәрим сызган туры юлдан
Баруыңда иман хак булыр.

Раббыбыздан иңгән китапларда
Яшәешнең асыл мәгънәсе.
Изге эшләр эшләп, гамәл кылсын
Дөньялыкта Алла бәндәсе.

Җиһан халкы көн-төн мәетенә
Юлласа да гамәл багышлап.
Тик үзенең гамәл дәфтәрендә
Язылганын алыр куш учлап.

Йә, Аллаһым, көн-төн булган кебек,
Явыз бәндәләр дә яраттың.
Гөнаһ булган начар гадәтләрне
Кавемнәргә биреп тараттың.

Йә, Аллаһым, нәфес колларына
Хәрәм бирдең, хәмер йоттырдың.
«Ни кылансаң, шуңа ирек», — диеп,
Кулларына кылыч тотырдың.

Йә, Аллаһым, Син фатыйха биргән
Юлбашчылар ярсып котырды.
Елга булып ага изге каннар
Һәм һаман да хаклык оттырды.

Йә, Аллаһым, гыйбрәт алыр өчен
Афәт бирдең денсез кавемгә.
Утка ягып, суда һәлак иттең —
Миллионлаган керде кабергә.

Йә, Аллаһым, сөйгән Адәмеңне
Азгынлыкта нигә йөртәсең?
Тәмуг ягып, гөнаһ ияләреп
Мәхшәр мәйданында көтәсең?!

Йә, Аллаһым, үзең чик куймасаң —
Адәмнәреңә шайтан азынды.
Әдәпсезлек, әхлак-гадәтсезлек
Тозагына кереп абынды.

Йә, Аллаһым, Сиңа табынганны
Мәрхүм итмә рәхмәт-шәфкатьтән.
Галәмнәрнең әнҗе бөртегедәй
Җир-Ананы итмә җәһәнәм.

Йә, Аллаһым, берүк, исеңдә тот!
Җир исемле Галәм валчыгын.
Шул валчыкта ыгы-зыгы килгән
Адәм дигән кызыл балчыгын.

Йә, Аллаһым, күпме зарлансак та,
Бу дөньяңнан килми китәсе.
Бөтен начар гадәтләрдән арынып,
Җирне иде җәннәт итәсе.

Йә, Аллаһым, кеше гомер буе
Кайгы-хәсрәт кичеп уздыра.
Ләкин якты, нурлы бу дөньяңны
Бер күрүе үзе ни тора!

Йә, Аллаһым, ризалыгың өчен
Гамәл кылулары күңелле.
Җир-Анабыз кебек игелекле,
Мәрхәмәтле кешe күңеле.

Йә, Аллаһым, бирмеш һәр көнеңне
Шөкерана кылып каршылыйм.
«Гөнаһ-хаталарым гафу ит?» — дип,
Көзеремне сиңа мин юллыйм.

Йә, Аллаһым, төгәл, гүзәл хуҗам,
Рәхмәтеңнән, берүк ташлама.
Мәңгелектә тәүге көнәремне
Тәмуг газабыннан башлама.

IV

Яшәүнең асылы шулдыр:
Якты дөньяга килеп,
«Сөбханаллаһ!» — дию, Җирнең
Ямь-гүзәллеген күреп.

Яшәүнең асылы шулдыр:
Җирдәге сый-нигъмәткә
Шөкерана итә-итә,
Җир-ананы сөймәктә.

Яшәүнең асылы шулдыр:
Юктан бар итүчегә,
Лә иләһә иләллаллаһу,
Дибез Хак Тәгаләгә.

Яшәүнең асылы шулдыр:
Диләс, иманлы булу.
Аллаһ бар һәм берлегенә
Намаз, гыйбадәт кылу.

Яшәүнең асылы шулдыр:
Тапкан, баккан анаңа,
Кирексә, җаныңны да бир!
Бурычлы һәркем аңа.

Яшәүнең асылы шулдыр:
Әтиең-әниеңне,

Гомер буе сый-хөрмәттә
Яшәтү газизеңне.

Яшәүнең асылы шулдыр:
Барның рәхәтен күрү.
Эшләп тапкан хәләл малның
Хуҗасы була белү.

Яшәүнең асылы шулдыр:
Изге кәсеп кылуда.
Малның зурлыгында түгел,
Бәрәкәте булуда.

Яшәүнең асылы шулдыр:
Намуслы тормыш сөрү.
Гомеркәйнең ахырынача
Яшәү кадерен белү.

Яшәүнең асылы шулдыр:
Күркәм гаилә кору.
Һәркем сокланырлык итеп,
Яратып тату тору.

Яшәүнең асылы шулдыр:
Туйлы-никахлы булу.
Сөйгәнеңә, туганыңа
Тугрылык саклап калу.

Яшәүнең асылы шулдыр:
Ил-җиргә хезмәт кылу.
Балаларга, оныкларга
Яхшыдан үрнәк булу.

Яшәүнең асылы шулдыр:
Милли нигез булдыру
Тамыры мөселман булган
Нәсел-нәсәп калдыру.

Яшәүнең асылы шулдыр:
Нәселең ерак китсен.
Хәләл гамәленнең көче
Җиде буынга җитсен.

Яшәүнең асылы шулдыр:
Ир белән хатын бердәм,
Фатыйха бирсен яшьләргә
Исламлы йортка түрдән.

Яшәүнең асылы шулдыр:
Варис булып калганнар,
Күз карасыдай сакласын
Әманәтне алганнар.

Яшәүнең асылы шулдыр:
Мохтаҗга ярдәм итү,
Изге эш-гамәлләр кылып,
Гомер ахырына җитү.

Яшәүнең асылы шулдыр:
Яхшылыкның чиге юк.
Яман нәфесең тыймыйча
Ялгыша күрмә, берүк.

Яшәүнең асылы шулдыр:
Җәннәт әһеле булу.
Аллаһ рәхмәт-шәфкатьендә
Мәңге яшәүдә калу.

Яшәүнең асылы шулдыр:
Аллаһ кушканны үтәү.
Рәхмәтләренә ирешеп,
Аңа хакыңны түләү.

V

Кешелекнең акыл ияләре
Сорау бирә һаман үзенә:
Ул Адәмме, әллә маймыл дәвамымы,
Кем мөһерен суккан йөзенә?

Маймыл булса, миллиард ел элек
Бик катлаулы чорлар, юл үткән.
Бер күзәнәкле җан үсә, үсә,
Кеше дигән затка җитлеккән.

Ләкин болар барда теория,
Галим Дарвин әйткән сүз генә.

Иксез-чиксез Галәм киңлегендә,
Бәлкем, түгел фәкать без генә?

Фәнгә, техникага һич билгесез
Мең-мең сорау әле җавапсыз.
Кем хуаҗасы шушы Галәмнәрнең?
Гаилә дә булмый хуҗасыз.

Маймыл бүген маймыл булып кала,
Үзгәреш юк һичбер нәрсәдә.
Нәсел башы маймыл булу белән
Килешмидер барча кемсәдә.

Фәннәрнең дә үсеш дәрәҗәсе
Алла барын-югын әйталмый.
Сәяхәттән кайткан космонавтлар
Илаһи зат бар дип, тәкърарлый.

Үзем, шәхсән, нәсел-нәсәпләрне
Адәм-Хәва, димен башлаган.
Хак Тәгалә фатыйхасын алып,
Ир һәм хатын җирдән атлаган.

Бу ике зат кулга кул тотынып,
Дәверләрне үтә бергәләп.
Аллаһ һәрчак алар калебендә,
Гыйбадәттә алар чүгәләп.

Аллаһының бар һәм барлегенә
Иманым нык, һич тә юк шигем.
Аның рәхмәт, шәфкать, кодрәтләре
Ача-яба язмыш ишегем.

Ул саклаучы, яклаучы да безне,
Һәрбер эше өстен, хикмәтле.
Намаз укып, дога кылганнарга
Мәрхәмәтле, юмарт, хөрмәтле.

Ул патшасы барлык җисемнәрнең,
Тереклекнең җирдә, күкләрдә.
Аның рухы бөтен тарафларда,
Синдә, миндә, яши күпләрдә.

Ләкин юктыр гәүдә төзелеше,
Рәвеше дә, калып-сурәте.
Ул кемгәдер охшаш зат түгелдер,
Юктыр ашау-эчү гадәте.

Йоклы һәм ял белмәс. Һәрчак уяу,
Армаган да булыр, талмаган.
Берәүне дә үзе тудырмаган,
Берәүдән дә үзе тумаган.

Күрмәсәк тә Аны, ләкин Ул бар,
Искән җиләр дә бит күренми.
Без иснәгән һавалар да төссез,
Анда атомнар да йөгерми.

Галәмнәрне күзгә күренмәгән
Биоэнергия ураган.
Ул илаһи кодрәт иясе дә,
Тудырмаган һәм дә тумаган.

Тик алар бар. Нәрчак хәрәкәттә,
Ният, гамәлләре-хезмәттә.
Шөкерана кылып яшә, Кеше!
Аллаһ вәгъдә иткән җәннәттә.

VI

Тик онытма! Аллаһ Ризалыгы
Өчен диеп гамәл кылырга.
Уразасын тотып, зәкят биреп,
Бисмилла әйтеп корбан чалырга.

Аллаһ олуг, Мөбәрәк һәм Бөек
Дәрәҗәсе тиңсез, мактаулы.
Аннан пакъ һәм саф зат һич тә юктыр,
Нуры гүзәл, иссмс дан-шанлы.

Хак Тәгалә-акыл җитмәс камил
Илаһи көч, кодрәт иясе.
Ахирәткәчә Аның ниндилеген
Һичкемнең дә юктыр беләсе.

Иманың нык, җаның изге булса,
Аллаһ нуры иңәр йөзеңә.

Мәрхәмәтле Рахмән дөньялыкта,
Рәхим бирер җәннәт үзенә.

И, син, Адәм! И, син Кызыл балчык!
Яшә дингә иман китереп.
Гыйбадәт кыл һәм бул игелекле,
Җаның кайтыр җиргә әйләнеп.

«Без — ди, Аллаһ — байлык, сәламәтлек,
Яхшылыклар сезгә юллыйбыз.
Ачлык, сырхау кебек яманлыклар
Җибәреп тә сезне сыныйбыз».

Мин дә үттем ошбу сынауларны,
Хозурыңа барыр чак җитте.
Дүрт яшемдә битемә ат типте,
Кырык көнгә башган аң китте.

Җиде яшьтә бата-калка актым,
Боллар белән язгы ташуда.
Черек бәрәңгеләр, башак җыйдым,
Кар сулары ерып басуда.

Адаштырып, әфган җирләренә
Күз ачкысыз буран ташлады.
Йә, Илаһым, үз рәхмәтең илә,
Бер ут алдан бара башлады.

Барган хәлдә трамвайдан сикерү,
Китереп салды юлның өстенә.
Ыжгырып узган мәлдә вагоннар,
Утыра идем рельс өстендә.

Утыз биш ел йөрәк бакасыннан,
Экземалардан да интегәм.
Йә, Аллаһым, бир хәерле гомер,
Шөкерана кылып, баш иям.

Аллаһ ураза гасте көнне
Бу дөньяга мине китергән.
Үзе теләгән кешесе итеп,
Тугры, дөрес юлга күндергән.

Гомерем буе Аның якынлыгын,
Мәрхәмәтен тоеп яшәдем.
Йөземне ак, җанымны пакь итәр,
Эшләр булсын диеп, эшләдем.

Хаталардан кеше хали түгел,
Яхшы-яман аша сынала.
«Анаң карынында да, — дия, Аллаһ,
Үзеңне гөнаһсыз санама».

Гафу итәм — диде Аллаһ берәү,
Тәүбә итеп, кылса гыйбадәт.
Кабатланмаса гөнаһ-хаталы
Яман булган әгәр бу гадәт.

Хак Тәгалә ризалыгы өчен
Диеп башкар изге эшләрең.
Китаплар анасы — Ләүхул-Мәгфуз
Теркәр яхшы — яман гамәлең.

Адәменә Аллаһ ирек кылды,
Акыл нигъмәтләрен мул бирде.
«Хәләл көчең белән тапканыңның,
Игелеген үзең күр» — диде.

Дөньядагы һәр җан иясенә
Хак тәгалә бурыч йөкләгән.
Мөселманның фарыз гамәлләре
Коръән, хәдисләрдә әйтелгән.

Туу, яшәү, сөю, фани дөнья —
Мәңгелекнең мизгел арасы.
Кулга тотып гамәл дәфтәрләрен
Аллаһ каршысына барасы.

Лә илләһә иллаллаһу безне
Тәмуг газабыннан чит тотар.
Мөселманның йөзен, Ислам нуры,
Аллаһ нуры, иман балкытыр.

Дин кардәшем, кан кардәшем, без бит
Мөхәммәт пәйгамбәр өммәте!
Жир-Ана гүзәлләрнең гүзәле,
Гүзәллерәк Аллаһ җәннәте.

Ана

I

Сабырлыкны әнкәм, кайдан алдың?
Мин үзем дә белмим, әлбәттә...
Хәсрәт чигеп ачлы-туклы яшәү
Гавамнәрдә керде гадәткә,

Кырык бернең ачы салкынында
Туң җир чукып, окоп казу да,
Кояш белән торып, ай тулганчы
Урак уру уттай басуда,

Бил тиентен карга бата-чума
Урман кисү, тиргә чыланып,
Туң сазлыкның салкын базларында
Интегүләр, торф чыгарып.

Күтәртмәле чабаталар киеп,
Симәнәгә таңнан йөгерү, —
Чана тартып, иңгә биштәр асып,
Язгы ташуларда юл йөрү.

Салкын көздә, кышкы буранларда
Иген сугу ачык ындырда...
Үгез җигеп, ашлык тапшырулар,
Көнен-төнен буран-яңгырда.

«Юл газабы — гүр газабы,» — диләр,
Бу мәхшәрнең кайда азагы?
Гүргә кереп ятудан да яман
Карлы суда йөрү газабы.

Һәммәсе дә синең баштан узды,
Һәммәсен дә үзең күтәрдең.
Мич артына кереп еласаң да,
Тешең кысып, сабыр үткәрдең.

Барысы да җаның аша үтте,
Йөрәгеңә яра, әз салып.
Гомереңне эшкә багышладың,
Сөйгәнеңнән яшьләй тол калып.

Ышанмадың соңгы сулышкача
«Ирең үлде» дигән хәбәргә...
Әтиемне үзеңнән дә артык
Син сөймәгән булсаң әгәрдә,

Язмас идем шигъри бу кыйссаны
Газиз әнкәм минем, сөеклем.
Миллионлаган кызлар, тол Аналар
Тугрылыгын күреп мин үстем.

Сөйгән ярым кайтыр, диеп алар,
Өмет баглап юлны күзләде.

Соңгы сулышында, аны дәшеп,
Бердән-берен көтте, эзләде.

Әтиемне сагынулардан син дә,
Шәшар хәлгә җиттең кайчакта.
Күңеленне сагыш баскан чакта,
Улың булды кайнар кочакта.

Үзең кебек дөрләп, өзгәләнеп,
Ярсып янган учак каршында.
Үчти-үчти сөйдең син улыңны,
Бәйнә-бәйнә сөйләп барсын да.

Габдуллаңнан килгән өчпочмаклы
Юл хатларын укып юандың.
Җан җылысы сеңгән шул хатларны
Күкрәгеңә кысып еладың.

Түземлекнең дә бардыр бер чиге,
Ач торуның чиге — зиратта.
Кызыл балчык өемнәре арҙы,
Кемнең кадерлесе чиратта?

Ай-һай авыр булды көн күрүләр,
Аягында иде чабата.
Авыл халкы черек бәрәңгедә,
Уйсулыкта әлс кар ята.

Былтыргыдан калган башакларны
Басулардан җыеп йөрделәр.
Һәм берәүләр зәңгәр башакларның,
Агуыннан чирләп үлделәр.

Иң авыр чор: базлар — бәрәңгесез,
Ә игеннәр әле — серкәдә.
Керосин һәм шырпы алырлык та
Акча дигәне юк кесәдә.

Эш көненә тигән өлешләрне
Җиткералмый үтте үзәкләр.
Өс-башларда — калдык иске-мыскы,
Ямау өсте ямау күлмәкләр.

Алабута, кузгалак, кычыткан
Сөттә пешкән авыл ашын да.
Киемнәрдән бөт яңгыры яуды,
Кыздырганда мунча ташында.

Бүлештегез, кайгы-хәсрәтләрне
Кич утырып, калып төннәрен.
Ир-атларның укып фронтлардан
Килгән, яхшы-яман хәбәрен.

II

Чыдаса да Кеше чыдар икән,
Түзәр икән шундый тормышка.

Ярты авыл ачлык кочагында,
Әҗәл йөри очтан бер очка.

Аяк баскан, таяк тота алган,
Ашъяулыкка төреп булганын,
Сырхауларга җылы шулпа илтә,
Сөт-каймакның баздан алганын.

Син дә, Анам, күршең Әминәгә,
Алып кердең тары боткасы.
Мәрхәмәтлек, бер-береңә ярдәм,
Булды чорның тормыш тоткасы.

Син дә, Анам, йөрәк-җан җылыңны
Нәүмизләргә юмарт өләштең.
Үзең кебек, тол калганнар белән,
Өметле тел белән сөйләштең.

Кайдан килде сиңа мондый кодрәт?
Иңнәреңә илне күтәрдең.
Изге эш-гамәлләреңне күреп,
Рәхмәтләре иңде күкләрнең.

Язлар килде, кояш балкып көлде,
Инсаннарга шатлык өләште.
Бер иртәдә дөнья көлә-көлә,
Сихри яме белән бүлеште.

Соснечтән энҗе кебек балкып,
Күз яшьләре акты бәйрәмдә.
Бүгенгеләр кебек кермәдең син
Кеше өлешенә, хәрәмгә.

Синең кебек изге Аналарга
Алтыннардан һәйкәл куярлык.
Ә син бүген — бер кадерсез карчык,
Икмәкгең юк тамак ялгарлык.

Хөкүмәтнең «Онытмадык!» — дигән,
Шигаре дә ялган сүз булды.
Үлемтеккә җыйган көмешеңне
Тартып алды, җилгә очырды.

Габдулланнан калган киемнәрне
Ялгый-ямый гомер итәсең.
Гадәтеңчә, тыныч, сабыр гына,
Шыпырт кына әҗәл көтәсең.

III

Сөт, йомырка, ипи, бәрәңгеңне
Ашың итеп гомер кичердең.
«Уф алаң»ны тартып, утын, печән,
Башка кирәгеңне китердең.

Ач булсаң да, салым түләттеләр,
Йомыркасын, йонын өйдереп.
Үзең каймый, ул үстердең сөеп,
Кырык җамау ыштан кидерсп.

Бәхет эзләп, киләчәген күзләп,
Улың китте шахта — Донбаска.
Көч-гайрәте булган яшь егеткә
Нигә акча эшләп алмаска?

Тик син көткән, заргып, өмет иткән,
Бәхет тәтемәде: аяпыч.
Картлыгыңда улың, оныкларың
Булалмады сиңа таяпыч.

Улың гына түгел, күпләр шулай
Офыкларга карап юл чыкты.
Тик күбесе хәмер дәрьясында,
Маржа кочагында тончыкты.

Тәүфыйкь китә икән аерылсаң,
Бисмиллалы анаң ашыннан.
Кайгы йөрми агач башларыннан,
Кайгы йөри адәм башыннан.

Алыштырсаң, әгәр сатсаң дисең,
Гореф-гадәт, ислам йоласын.

Үз анаңны, туган телне җуйсаң,
Чит-ятларга кадер кыласың.

Баланң кылган гөнаһ-хаталарны
Баш орсаң да булмый төзәтеп.
Язмышларны Аллаһ хәл итсә дә,
Тормышыңны була үзгәртеп.

Табигать тә гел үзгәреп тора...
Кыш үтүгә, ямьле яз килә.
Табигатьнең кеше — асыл заты,
Кануннарын аның ул белә.

Ата-ана фатыйхасын алган
Гаиләләрдә иман терәге.
Сәрхүш баштан кушылганнарның тик
Җимерелә нәсел терәве.

Хат язмады улың бер тапкыр да,
Күчтәнәч тә сиңа салмады.
Шахталарга төшеп вафат булды,
Аны шулай Алла каргады.

IV

Сөялгән дә карчык җил капкага,
Терәп куйган җиргә таягын.
Әйтерсең лә беренче кат күрә,
Хәйран калып күзли як-ягын.

Йа, Илаһым, нинди гаҗәп дөньяң!
Һәр тарафта камил төгәллек.
Акыл җитмәс серле бу дөньяңда,
Төгәллектә икән гүзәллек.

Җисемнәрнең Галәм хәрәкәте
Арасына кыл да сыймаслык.
Табигатьнең тиңсез могҗизасын,
Бер күрүе үзе зур шатлык.

Өй түрендә шомырт чәчәк аткан,
Карчык белән бергә картайган.
Киртә буйлап үскән кычыткаһнар,
Тирә-якта үлән буй алган.

Язгы шаян, иркә, җылы нурлар
Куеннарга керен оялый.
Шифа бирсп тән, күзәнәкләргә,
Тамырларда йөреп дәвалый.

Күпме газап чигеп көн итсәң дә,
Картайсаң да, килә торасы.
Бар тереклек Җир-Анага гашыйк,
Дөнья үзе тылсым оясы.

Хәйран калып басып тора Ана —
Кешелеккә дәвам бирүче.

Җиргә хуҗа итеп җибәрелгән,
Аллаһының мәгърүр илчесе.

Басып тора илгә ир, ул биргән
Ихтирамга лаек гали зат.
Акыл-фигыль, гүзәллекне аңа
Мөлдерәмә биргән табигать.

Инде саулык, көч-куәте дә ким,
Буй-сыннары калган бөрешеп.
Намаз саен меңь рәхмәтләр әйтә,
Булган кадәренә килешеп.

Шөкерана кыла яшәвенә,
Таласа да үзен меңь сырхау.
Бүгенгедәй гүзәл ал таңнарны
Өмет бирә күрү, җан чыкмау.

Ирс, улы чыккан бусагалар
Ишегалды якка чүккәннәр.
Таягына ауган хуҗасы күк,
Каралтылар тузып беткәннәр.

V

Хәбибҗамал карчык үткәннәрне
Кабат-кабат барлап күңлендә,
Ничәнче кат хәтер катламнарын
Әйләндерә йөрәк түрендә.

Әнә, алар Габдулласы белән
Тормыш башлый сыңар кашыктан.
Көзен мунча кадәр йорт коралар,
Эш көненә тигән ашлыктан.

Габдулласы — дан балта остасы,
Йортлар салды, илгә ялланып.
Үзе чүвәк, читек-кәвеш текте,
Өч-дүрт сәгать төнгә ял алып.

Тырын табар, ташка кадак кагар,
Калкып чыкты күркәм яңа йорт.
Яңа йортның күрке булсын дисәң,
Нәсел агачыңны син утырт.

Көнләшепме нәни шул бәхеттән?
Илдә купты сугыш афәте.
Туган җирне, мәхәббәтне яклау —
Ир-атларның асыл нәүбәте.

Урамнарны урап бәхилләште,
Саубуллашты гаярь ир-затлар.
Үзәк өзгеч аһең, җыр-моңнардан
Тетрәнеп куйды пар-атлар.

Габдулласы, тальян гармун уйнап,
Уртасында булды арбаның.

Иңнәреннән кочаклащкан ирләр
Тирәннәрен салды яраның.

Сагыш тулы ярсу җан җырлары
Бәгырьләргә керде уелып.
Кочактагы имчәк балалар да,
Шиңгән гөлдәй калды боегып.

Төсе булып тик гармуны калды,
Җылы куенында — баласы.
Ирен, улын югалтудан алган
Әрнеп торган йөрәк ярасы.

Ирсез калды, газиз улсыз калды,
Илкәеннән нәрсә, ни алды?
Чит җирләрдә ирләр туфрак булды,
Нәсел-нәсәбәләр югалды.

Җиргә килеп, үксез ялгыз торып,
Күрде нинди тормыш рәхәтен?
Көнне төнгә ялгап эшләсә дә,
Ишетмәде иле рәхмәтен.

И, син, Ана, хәйлә, мәкер күрдең,
Белдең ирең, улың әҗәлен,
Хәләл ризык ашап гомер иттең,
Бирсен Алла савап, әҗерен.

И хатын-кыз!..

И, хатын-кыз, кем син? Фәрештәме?
Аллаһыңмы әллә шәүләсе?
Әллә җиргә токым үрчетергә
Җибәрелгән Галәм бәндәсе?

Алиһәлек, кодрәт, илаһилык
Аллаһыдан әллә салынган?
Камиллегең, серле гүзәллегең
Галәм, Кояш, Айдан алынган?

Кем син? Хәтта Алла каргышыннан
Курыкмыйча алма өзүче?
Кеше дигән могҗизалы затка
Яшәү биреп учак өрүче?

Ир-атларның күңеленә утлы
Наз, Мәхәббәт, Сөю саласың.
Дөньяларның бөтен мәшәкатен
Иңнәреңдә тартып барасың.

Әле генә син — ата баласы,
Әле генә — сөю ярасы.
Әле генә үзең — гади хатын,
Үзең пәйгамбәрләр Анасы!

Кем син? Сихри, нәфис, сылу ханым,
Үзең чибәр, үзең сөйкемле?! —
Үзең юмарт, шәфкать-миһербанлы,
Алыштырдың Җирдә син кемне?

II

И, хатын-кыз! Илаһи зат итеп,
Һәрчак сиңа караш ташладым.
Яшерен сөеп, эчтән генә көеп,
Гомер кичтем, гомер башладым.

Иркәләгән дә — син, яраткан да,
Нуры да син җирдә тормышның,
Изге ният белән яшәү биргән
Бисмилласы тәкъдир-язмышның.

Хак Тәгалә юкны бар итүче!
Җир-Анабыз юмарт сый бирә!
Ә, хатын-кыз, сөеп һәм яратып,
Җирдә алмаш — Кеше үстерә.

Анасының тылсым күкрәгеннән
Имчәк бала ала нигъмәтен,
Мәхәббәтнең күкрәп яшәвендә —
Ир-ат тоя сөю кодрәтен.

Караттыра, яраттыра белгән
Якты йолдыз, йөзек кашыдай.
Елмаюың җанда ут уйната,
Карашларың — яшен ташыдай.

Итәгатьлек, сабыр-түземлегең
Ихтыярың килә йөрәктән.
Әхлак-әдәп, тәртип һәм тәрбия —
Хатын-кызга бәйле, димәктән!

Зирәклегең, акыл, таңкырлыгың —
Иланһының тиңсез бүләге.
Адәм булып Җиргә килү өчен,
Шул бүләкнең булган кирәге.

Фигыль-холкың, рухи ихтыяҗың
Риза булмый җәннәт ашына.
Ярты алма бирсп, йөгән салдың
Гамь-шөгыльсез Адәм башына.

Теләмәдс сау-сәламәт рухың
Җәннәт колы булып калырга.
Син ашкындың Адәм белән бергә,
Җирдә яшәп, ләззәт алырга.

Үрсәләнде нәүмиз саф күңелең
Мәлдерәмә сөю, наз тулы.

Җылы куеныңда иркәләнде
Хыялыңда йөргән Җир улы.

Ай-Кояшлы якты бу дөньяда
Килде синең Ана буласың.
Әни булып, сөеп һәм сөелеп,
Бу Җиһанга игелек кыласың.

Хатын булып, ир-ат төмен тоеп,
Гаилә корып, Җирдә яшисең.
Бала дигән татлы-утлы затның
Күреп шатлык, ачы-төчесен.

Ни яме бар дөнья, табигатьнең —
Язлар килеп, бөре шытмаса?
Ни яме бар Җирнең, әгәр анда
Болын-кырлар, урман булмаса?

Тәвәккәләп әгәр син килмәсәң,
Мәхрүм булыр иде Җир-Ана.
Һәрбер Ана үз баласын кочып,
Гаилә учагында юана.

Кайгы-хәсрәт, газап-михнәт күреп,
Сафланса да кешс күңелс.
Һәркем Җиргә шат, бәхетлс булып,
Яшәр өчен килә, билгеле.

Җир-Ананың яме, гүзәллеге —
Күчермәсе бакый җәннәтнең.
Бер күрүе үзе чиксез бәхет,
Кадерен белсәң шушы кыйммәтнең.

Гади генә сыман үсемлекләр,
Һәрбер җан иясе — могҗиза.
Рәхәтен күр дисп, Алла биргән
Шушы байлыкларга син — хуҗа.

Дөньяга — ямь, тормышка тәм биреп,
Яши кеше, кылып тантана.
Яшә, Ана — игелекле җан син,
Яшә Галәм, яшә Җир-Ана!

III

И, мөкатдәс татар хатын-кызы!
Үзең — горур, кыю, тәвәккәл.
Милләтеңә асыл дәвам биргән
Гыйбадәтле, тыйнак, син — гүзәл!

Аллаһыдан иңгән иман нуры,
Ислам дине балкый үзеңдә.
Һәва-Ана Җәннәттә тешләгән
Алма алсулыгы йөзеңдә.

Миһербанлык, шәфкать, инсафлыгың
Әби-бабаң мирас бүләге.
Төс-кыяфәт, күркәм буй-сыныңда —
Татарларның милләт бизәге.

Чыныктырды сине Дала җиле,
Иркәлидер Идел кояшы.
Сихәт-куәт бирә Җир-Ананың
Бисмилланны әйткән сый-ашы.

Күңел күгең — йолдызлы төн кебек
Сер сандыгы, сихри тирәнлек.
Нарасыдай ихлас елмаюың
Язгы гөл бакчага тиңнәрлек.

Сөелү һәм яну-көю өчен,
Кирәк булган Җиргә килүең.
Үзенә бер мәгънә бирә сыман,
Үпкәләвең, «дулый» белүең.

Мөселманлык, әхлак кануннары
Мирас итеп сиңа бирелгән.
Гасырларның тиңсез хәзинәсен
Милләт өчен сакла дислгән.

Әби-бабаң Ислам тәрбиясен,
Әдәп-гадәт, йола калдырган.

Аерылган башлар гәүдәләрдән,
Аерылмаган нәсел тамырдан!

Кылыч аша үткән шәһитләрнең —
Шәкертләрнең рухын рәнҗетмә.
Милләтенең тамырларын кискән
Төссез-хиссез манкорт үрчетмә!

Рәнҗемәсен чиркәү нигезенә
Кыстырылган кабер ташлары.
«Лә илләһә Илләл-лаһу!» — диеп,
Шәһит киткән өммәт башлары.

Һәр каһемне Алла үз иманы,
Үз мәсләге белән яраткан, —
«Үз ишеңә ин-кардәш бул!» — диеп,
Фатыйхасын биреп тараткан.

Үзебезнең гореф-гадәтләрдән
Мәхрүм итмә газиз баланны.
Хәер-дога ннан ташлама, берүк,
Күптән мәрхүм әби-бабаңны.

Һәлакәткә илтмә нәселеңне,
Милләтсезә итмә хыянәт.
Тамырыңнан аккан татар каны —
Татарыңа булсын әманәт.

Чын татар бул! Милли горурлыгың
Югалмасын барыр юлыңда.
Ятлар арбасында бара калсаң,
Дилбегәсе булсын кулыңда.

Буыннарның бердәмлеген сакла,
Милләтеңнең акла өметен.
Суырып ал, читләр куснында
Кыйбла җуйган татар егетен.

Яхшылыгың җирдә ятып калмас,
Игелектән шытыр игелек.
Ислам берләштергән кыз-егетнең
Кан-тамыры булыр мәңгелек.

Коръән-Кәрим тотып, балаң калыр
Иң макатдәс теләк, уй белән.
Бисмиллалы эш-гамәлең калыр
Дәүләт белән, халкың, ил белән.

И, асыл зат — татар хатын-кызы,
Холкың — күркәм, үзең — сөйкемле.
Ятлар белән ятма, динең сакла,
Бул намазлы әбиең шикелле!

Хәрәм ашап, хәрам эчкән йортка
Бәрәкәтле бәхет иңмәчәк.

Чәчең белән җирен себерсәң дә,
Чит милләткә син — тик килмешәк.

IV

Татар телле, Ислам динле булу
Һич китерми йөзгә кызыллык.
Тел, динебез — дөнья тирәли без
Аяк терәп җирдә торырлык.

Нәселебез Мисыр, Шумерлардан
Утлар-сулар кичеп береккән.
Дистә меңь ел төрки кавем булып,
Данлы-шанлы мәшһүр юл үткән

Ул юлларда авыл һәм шәһәрләр,
Хәшәр хәзинәсс күмелгән.
Мәгърифәт, фән, сәнгать, әдәбият
Асыл энҗеләре сибелгән.

Милләт Аналары! Рәхмәт әйтеп,
Башым иям сезләр алдында.
Җир нигъмәте, җәннәт рәхәтләре
Аналарның аяк астында.

Тик бер Алла — тиңсез һәм мәңгелек
Иксез-чиксез бакый Галәмдә.
Хатын-кызның җирдә мәңгелеге —
Ана була алган гамәлдә.

Багышлау

Дөньядагы һәрбер җан иясен
Аллаһ парлы итеп яраткан.
«Бер җан, бер тән булып яшәгез»,— дип,
Мәхлукларын Җиргә тараткан.

Адәмен ул Җиргә хуҗа иткән,
Акыл, фикер, ике кул биреп.
«Эшлән тапкан хәләл мөлкәтеңнең
Шатлык, игелеген күр,» — диеп.

Биргән сөю, биргән хис, мәхәббәт,
Бер-береңне назла, ир-хатын!
Никах кылып, ата-ана булып,
Бурычыңның түлә үз хакын.

«Таш атканга хәләл ашың юлла,
Адәмсмә кылма явызлык.
Барыша син бел канәгать була,
Алдамасын хәрәм мал, азык».

Ләкин нәфес колы булырыма
Җитә калган ярты алма да.
Хәва-Адәм кылган гөнаһларны
Кичермәгән хәтта Алла да.

Дошман күрә бүре токымы да
Бер сәяккә мәсләк сатканны,
Узган-барганнарга койрык болгап,
Уйнаш — азгын караш аткынны.

Кайчак үлем белән тәмамлана
Нәсел-нәсәбләргә хыянәт.
Бер-бер артлы, ярлар алышудан
Дөньяларга килә кыямәт.

Пар атларның төпкә җиңелгәне —
Сиңа багышланган дигәнс.
Ян-якларда уйнаклашып чапкан —
Тәнен сатып, читтә йөргәне.

Ничек кенә язмыш кыйнаса да,
Нәфес колы булма, тезләнмә!
Чит-ятларның күңелен күрим дип,
Боргаланма, ике йөзләнмә!

И, син, кеше! Бөек җан иясе,
Мөлдерәмә акыл, фикерең.
Ник үзара ызгыш-талашларда,
Ялгышларда үтә гомерең.

I

Барысын да бәхилләде әҗәл.
Тынып калды яман ызгышлар, —
Савыт-саба шалтыраган чаклар,
Чебеннән фил ясап кызышлар.

Барысы да — сукыр бер тиенлек,
Бәһасе юк гаилә чүпләре.
Күңелемнән барлыйм үткәннәрне:
Мәгънәсезлек булган күпләрс.

Яхшы-яман, оят-оятсызлык,
Синең белән һәрчак янәшә.
Гомере буе кеше карашлыклы,
Гадәтләре белән көрәшә.

Бәхет-тәүфыйк, нәфес, хөсетлек тә
Үзең белән атлый бергәләп.
Явызлык һәм намус кешеләрне
Бай, фәкыйрьгә куя бүлгәләп.

Бернәрсә дә үтми эзсез генә,
Өлешеңә тигән көмешең.
Гомер озынлыгын тәгаенли
Әдәп-әхлак һәм көнкүрешең.

Кыңгыр эшең өчен дөньялыкта
Котылсаң да, җәза алудан,

Тегесендә — тәмуг кисәвс син,
Котылгысыз йолын калудан.

Бернәрсә дә үтми әзсез генә
Нәрсә чәчсәң — шуны җыясың.
Җирдә кылган яхшы-яманлыкны
Җиде буыннарда тоясың.

Үткәннәргә борылып карыйсың да,
Чәчләр үрә тора кылмышка.
«Юк-юк! Монда тормыш гаепле!» — дип
Аударасың заман, язмышка.

Гасырлардан гасырларга күчә
Бер үк ялгыш, гөнаһ, хаталар.
Каберләрдә хәмер әчеп үлгән,
Япь-яшь асыл затлар яталар.

Берәү — ялгыш, берәү — күрә торып,
Белә торып баса тырмага.
Диңле кеше намуслы юл сайлый,
Иманлы юл тормыш кормага.

II

Моңа кадәр уйланмыйча йөргән
Уйларыңа урап кайтканда:

Үткәннәрне барлап, өмет белән
Хастаханәләрдә яткында.
«Их, — дигәнсең — булса гомеркәем,
Белер идем аның кадерен...
Яшәр идем күркәм ана булып,

Оныкларыма җай кылып,
Шөкерана әйтеп бер Аллага,
Соңа калдым, ахры, тәүбәгә?
Үтте гомерем, үтте заяга.
Булмадым тугрылыклы хатын,
Уларыма — әдәпле ана.
Үкенүләрдән инде юк файда,
Үтте гомерем әрәм, заяга
Гөнаһ җыеп шушы дөньяда.
«Истигъфар кыл», — диям Аллага.

Яшь чагында куәт, сәламәтлек,
Бетмәс кебек итеп тоябыз.
Аллаһ биргән гомер-хәзинәсен
Юкка-барга исраф кылабыз.

Тегесендә — тәмуг кисәвс син,
Котылгысыз йолып калудан.

Бернәрсә дә утми эзсез генә
Нәрсә чәчсең — шуны җыясың.
Җирдә кылган яхшы-яманлыкны
Җидс буынларда тоясың.

Үткәннәргә борылып карыйсың да,
Чәчләр үрә тора кылмышка.
«Юк-юк! Монда тормыш гаепле!» — дип
Аударасың заман, язмышка.

Гасырлардан гасырларга күчә
Бер үк ялгыш, гөнаһ, хаталар.
Каберләрдә хәмер эчеп үлгән,
Япь-яшь асыл затлар яталар.

Берәү — ялгыш, берәү — күрә торып,
Белә торып баса тырмага.
Динле кеше намуслы юл сайлый,
Иманлы юл тормыш кормага.

II

Моңа кадәр уйланмыйча йөргән
Уйларыңа урап кайтканда:

Үткәннәрне барлап, өмет белән
Хастаханәләрдә яткanda.
«Их, — дигәнсең — булса гомеркәем,
Белер идем аның кадерен...
Яшәр идем күркәм ана булып,

Оныk-уллarыма җай кылып,
Шөкерана әйтеп бер Аллага,
Соңа калдым, ахры, тәүбәгә?
Үтте гомерем, үтте заяга.
Булмадым тугырылыклы хатын,
Улларыма — әдәпле ана.
Үкенүләрдән инде юк файда,
Үтте гомерем әрәм, заяга
Гөнаһ җыеп шушы дөньяда.
«Истигъфар кыл», — диям Аллага.

Яшь чагында куәт, сәламәтлек,
Бетмәс кебек итеп тоябыз.
Аллаһ биргән гомер-хәзинәсен
Юкка-барга исраф кылабыз.

Кунак булып без Җиргә килсәк тә,
Тыйнак кына була белмибез.
Аллаһының хәер, нигъмәтенә
Хәмер, зина белән түлибез.

Әни мәрхүм әйтә торган иде:
«Тәүфыйксызга бар, дип, ике юл.
Икесе дә афәт-фаҗигале:
Берсе — төрмә, берсе — соңгы юл».

Икесен дә үттең, ташлап киттең
Гөнаһларың чыкты бүселеп.
Тишек көймә суга тонып батты,
Кипкән мичкә төште ишелеп.

Шешә кочып, кулдан-кулга күчеп,
Унҗиде ел гомер кичердең.
Сөеп, сөзлеп яшәр елларыңның
Чәчкәләрен җилгә очырдың.

Котмәгәндә иртә килгән әҗәл
Үзенә дә сәер тоелды.
Әйтерсең ул, юл барышлый гына,
Ялгыш кына сиңа кагылды.

Елап үлдең, елап гүргә кердең,
Күз яшьләрең ниләр сөйләде?
Телең әйтә алмаганны ымлап,
Бәхилләшмәк әллә теләде?

Табибларның «үлде» дигәннәре
Әллә булды мәрткә китүсең?
«Туганнарым, зинһар, ашыкмагыз,
Мин тере бит әле,» — диюсең?

Сорашсам да моның сәбәпләрен,
Тик әмәлсез калды бу гамәл.
Шик-шөбһаләр телә бәгыремне,
Тәгаенсез булдың син, әҗәл!

Бернәрсә дә үтми әзсез генә,
Һәркем кичәр сират күперен.
Ачлы-туклы сукбайлыкта йөрү
Гомереңә сукты мөһерен.

Мирас булып күчә буыннарга
Дөньялыкта кылган гамәлең.
Әдәп-әхлак булып дәвам итә
Варисларда рухи яшәвең.

Дәвам итә явызлык та булып,
Яманлык та — Җирдә калдырган.
Меңкат яман, явыз гамәлләр дә
Данга күмеп булса язылган.

Хак Тәгалә аңлы Адәменә
Мулдан биргән байлык, ирекне.
Ни эшләсәң, нәрсә кылансаң да —
Ошбу дөньяда син ирекле.

Кояшлы көн кара төнгә керә,
Язлар көзләр белән алыша.
Җавап бирәсеңне тик онытма,
Мәхшәр көндә булыр тамаша.

Мәңгелеккә барыр юлга чыккан,
Кешеләр без, җирдә яралган.
Тик кунагы шушы могҗизалы,
Тукталышның, «Җир» дип аталган.

III

Үлгән көнне йөзең көләч иде,
Ирен читләрендә — елмаю.
Тик иртәсен, кинәт үзгәрдең дә,
Йөзләреңә кунды моңаю.

Үзең кайгы, хәсрәт кичергәндәй,
Каш араңа сырлар уелды.
Син кемгәдер үпкәләгән сыман,
Хәтереңә калган кебек тоелды.

Чытырдатып йомган күзләреңнән
Саркып-саркып акты күз яшең.
Вакыт-вакыт, әллә өнгә килеп,
Йөз үзгәртеп, безгә эндәштең?

Юып салгач, янә шаккатырдың:
Илаһи нур иңде йөзеңә.

Әйтерсең лә, Хак Тәгалә килеп:
«Хур кызы син» дидe үзеңә.

Тәүбә итеп, уразалар тоту,
Намаз уку, хаҗга сәяхәт.
Зякәт, фитыр, чалган корбаннарың
Мәхшәр көндә бирсен бәрәкәт.

Йә Аллаһым! Изге теләкләрем,
Догаларым аңа иреште.
Насыйп әйлә, кодрәтләреңә илә,
Җәннәтеңдә безне күрештер.

IV

Арба, чаналарның түгәрәкләре
Сикәлтәле юллар гаепле.
Тормыш чалуында мәтәлгәннәр,
Кемгә түгелергә гаепме?

Борынгылар әйткән: «Гөнаһ-гаеп
Тәртәдә дә, — диеп, — атта да».
Атсыз тәрәзә — ул хуҗасыз киртә.
Хуҗа кирәк һәр ир-атка да!

Төпкә җигелеп, тормыш арбаларын
Тартсын ир-ат, типми тәртәгә.
Гаилә кору, күркәм ата булу
Үзе шөһрәт, үзе мәртәбә.

Үзем кем соң? Бүреләрдәй тугры,
Тату гаилә корган ир-атмы?
Әллә язмыш, тормышны гаеплән,
Ыңгырашкан мәхлүк бер затмы?

Мин дә — каһәр заманның баласы,
Артыгы да түгел, киме дә.
Адәм рәтле гаилә коралмаган,
Булалмаган тугры бүре дә.

Безнең заман (тагы аңа сылтау) —
Хатын-кызның хокук алганы.
Дөнья эшен, гаилә мәшәкатен
Үз иңенә өеп салганы.

Ә без, ирләр, социализм биргән
Сәдаканы аңа тоттырдык.
Ата-баба гадәтләрен тотмый
Икебез дә бердәй оттырдык.

Адәм рәтле яши алмасак та,
Мулдан булды бездә зәһәрлек.
Муллаларны аттык, иман саттык,
Хәрәм ашап, хәмер чөмердек.

«Интәшләр»гә койрык болгый-болгый,
Күкрәк сугып сүктек Алланы.
Күтәрәмгә калдык эшли-тәзи
Коммунизм дигән ялганны.

Ялган сөйләп, хәйлә-мәкер кордык
Дөньябызны уран хәтәргә.
Коралларның койдык дәһшәтлесен,
Халыкларны харап итәргә.

Бернәрсә дә үтми эзсез генә,
Яман гадәт — ул баш казыгы.
Бер яхшылык мең яхшылык бирсп,
Исәннәргә бул, җан азыгы.

Хак Тәгаләм, дингә кайтканнарны
Рәхмәт, шәфкатеңнән ташлама.
Әхлаклы ит Адәмеңне, Аллам,
Кылма һәлак, итмә ашлама.

Мәңгелеккә, ахры, аерылдык...
И хатыным, инде бәхил бул.
Сине яклый, саклый алмавымны
Кичер, җаным, инде гафу кыл.

Моң

(Трагик ода)

Татар моңы телә бәгырьләрнс,
Үзәкләрне өзә таңнарда.
Сагыш ташый, өмет хыял ташый,
Ярсу хисләр ташый аңарда.

«Кара да гына урман, караңгы төн,
Яхшы атлар кирәк лә үтәргә.
Заманалар авыр, еллар ябык,
Дус-иш кирәк гомер итәргә».

Яхшы атлар, дус-иш кирәк булган
Дөнья көтәр өчен бабама.
Тормышлары кара урман сыман
Кайсы гына чорны карама.

Сыенган да урман куенына,
Ут тергезеп, гомер кичергән.
Кичке учак ялкынына карап,
Ах-зарларын моңга күчергән.

Тирән, тиңсез моң сагышы аша
Оныкларга гыйбрәт сөйләгән.
Утта янган данлы Идел-йортын
Үҗәтләнеп кат-кат сипләгән.

Ач бүредәй кансыз, явыз дошман
Янә килеп, Илне туздырган.
Халкын, хәтта сабыена кадәр,
Канлы кылыч аша уздырган.

Күз алдымнан үтә бабаларның
Кан-яшь түккән мәхшәр заманы.
Ыңгырашып ауган манаралар,
Тынып калган җомга азаны.

Ил күкрәген кылыч ярып үткән
Илбасарның тәре кулында.
«Лә иләһә иллаллаһу» — диеп,
Васыять әйтә ата улына.

Татар иле алсу шәфәкъ төстә.
Илбасарның кулы пәкедә.
Чукынмаган ата-аналарны,
Балаларны тынчый бәкедә.

Туган белән туган якалаша
Бер-беренә ядрә, ук атып.
Татарымның көнчел-хөсетлеге
Ханлыкларны китте таратып.

Төтен, сөрем, янгыннар эченнән
Ишетелә бала тавышы.
Богауларны өзеп, азат итәр
Көч-кодрәтле вакыт агышы.

Һәр тарафтан татар моңы ташый.
Җыр-моңнарда сагыш, үч, көрәш.
Бугазымда чорлар зар-газабы,
Күзләремдә мөлдерәмә яшь.

Әрвахларның җәрәхәтле җаны
Үкси сыман моңга кушылып.
Бәддогасы ташый илбасарга,
Рәнҗү-каргыш ташый моң булып.

Ассалар да аны, киссәләр дә,
Иманында калган чын татар.
Гаделлекне даулап зур көрәшкә,
Баскан татар өчен таң атар!

Һәр тарафтан татар моңы ташый —
Аерылганның ачы язмышы.
Бүленгәннең бүре арасында
Койрык кысып гомер узмышы.

Улы-кызы тол анасын ташлап,
Читкә киткән, чыкса бер җае.
Икмәк эзләп шахталарга җиткән
Ач-ялангач татар малае.

«Шахтер егет күмер кисә,
Кемнәр ала исәбен?
Гомерем бетеп, таш басмаса,
Ташламам җан кисәгем».

Донбассларда кыйбла югалтканның
Кемнәр алыр икән исәбен?
Маржа кочагында шыңшый-шыңшый,
Көчек булган татар кисәген?

Килмешәккә калган гореф-гадәт,
Иман-әхлак, әреп югалган.
Үзен Гена иткән Габдуллажан,
Балалары урыс саналган.

Чүчка белән хәмер буталганнан
Мәнкорт дигән бәндә яралды.
Ике арада калган буфер татар
Кара күмер сымак каралды.

Кылган гөнаһ, ялгыш-хаталарны
Сылтап булыр иде заманга.
Һәммәсенә, имеш, чор гаепле,
Шул аклану бездә һаман да.

Тик берәү дә сырлы стаканнан
Авызларга хәмер салмады.
Шайтан коткысына бирелгәннәр
Упкыннарга карап атлады.

Мөлдерәмә күз яшьләрем аша
Үткәннәрне барлыйм сискәнеп.
Ачлы-туклы ятим бала чагым,
Йөргәннәрем эттәй иснәнеп.

Язмыш безнең баштан сыйпамады
Иңгә салды тормыш тәртәсен.
Бала чактан авыр камыт киеп,
Башладык без гомер иртәсен.

Чүл-далада үскән лалә кебек,
Кечкенәдән шиңдек, бөрештек.
Бәхетсезлек, кара сакал булды,
Ялган белән һәрчак күрештек.

Илнең гигант төзелешләрен иңләп
Күп чөмердек «Лаеш шулпасы»н.
Танканнарны каптык күмәкләшеп,
Кыерсытмый урыс йоласын.

Алдау-йолдау, ялган, буш вәгъдәләр
Татар балаларын таратты.
Дала кылганыдай сөрелгәннәр,
Себер китеп башын югалтты.

Һәр тарафтан татар моңы ташый,
Урыс җырлый татар җырына:
«Утыр әле яннарыма,
Ял булсын җаннарыма».

Шешә тотып җырлый, бии торгач,
Якынайтты җанга араны, —
Йомшак җәеп урыс катысына
Утырттылар мескен татарны.

Ир-егетләр маржа кочагында,
Урыс үбә татар чибәрен.
Ата-улны, ана-кызны белми,
Тоймый татар гүргә кергәнен.

Манкорт татар бүген табан ялый,
Мулла белән мулла чәкәшә.
Татар йөзле егет-кызларыбыз
Чит-ятларга токым өләшә.

Күпме кияү, күпме килен өчен
Сукыр тиен милләт кыйммәте.
Тәрс таккан кәфер кочагында
Гарипләнә ислам өммәте.

Туй ясаган йөзнең кырык дүрте
Кушылганга башка милләткә.
Милли хисе, милли горурлыгы
Җилгә оча — калмый иләктә.

Чит-ятларга күркәм кырык дүрт пар —
Алар мәллә сәю әсбабы?
Бүгенгенең Камай, Шахгалие
Бетсен диме татар нәсәбе?

Милләтенә, үз-үзенә хөрмәт
Ник юк безнең Гали, Галиядә?
Үз кыйбласын гомер тапмаячак
Гибрид үсә катнаш гаиләдә.

Гибрид егет, гибрид кыз баланың
Богы да юк, юктыр Алласы.
Денсез-динсез, Коръән һәм Инҗилсез
Гыйфрит иле — Урыс дөньясы.

Аеп җуйган бисмилласыз татар
Көнем өчен диеп көн күрә.
Эттән туган бүре балаларын
Эт үз итми, бүре ят күрә.

Мин — фәкыйрең, булам дәү әтисе
Төссез, хиссез шушы токымның.
Урыс телле шушы корбан токым
Нурын куа ата йортының...

Киленнәрем кяфер, оныкларым —
Бисмилласыз татар барысы да.
Йа Аллаһым, ни дип җавап бирим,
Хозурыңа баргач, каршыңа?

Ни дип җавап бирим кылыч аша
Шәһит киткән бабам рухына?
Милли хис вә милли горурлык бир,
Урыс телле кызым, улыма.

Иман бирсен Аллам онытма,
Кул күтәреп дога укырлык.
«Монда минем дәү әтием», — дисеп,
Каберемә зират кылырлык.

И, татарым, җүләр кан алмашу,
Урыс булуыңда ни мәгънә?
Теш ыржайту, талаш, кыйнаш, сугыш...
Шул булдымы милли хәзинә?

Һәр тарафтан татар моңы ташый —
Ерак гасырларның авазы.
Шушы аваз, шушы моңлы аһәң
Татарымның күңел, җан сазы.

Әле язгы ташкын булып ташый
Кырлар ята моңга төрелеп.
Әле иртәнге җил, талгын гына,
Назлый сыман биттән үрелеп.

Шау чәчәкле гүзәл иркен дала
Моңга сарган гүя кодрәтен.
Чуен койган болгар остасының
Җырлы иткән хәләл хезмәтен.

Илләр иңләп йөргән дәрвиш кебек
Җыр-моң сөйли вакыт агышын.
Дан-шөһрәтле олпат бабамнарның
Дошман белән билләр алышын.

Чын татарын сөя һәм иркәли
Тальян моңы, курай аһәңе.
Ул үзенчә сыный татарлыкны,
Татарына бирә бәһане.

Илаһи моңҙ! Илһам, коч-кодрәтең
Рухи сафлык бирсен татарга.
Коръән, Иман белән култыклашып,
Насыйп булсын бергә атларга!

Йә, әйт, Хаким! Мондый илаһи моң,
Сихри моң бар кайсы милләттә?
Кайсы милләт үзен, моңын саклап,
Исән калган меңҙ кат иләп тә!

Кайсы милләт күрше дәүләтләрен
Асыл ирләр белән ныгыткан?
Әнә шулар төркиләрнең башын
Урыстан да узып кырыккан.

Алтын-көмеш, бүләк, мал-мөлкәтләр
Һушын алган сатлык затларның.
Дәүләтләрен килеп тар-мар иткән,
Сатлык улы шул ук татарның.

Каршы куйган патша милләтләрне,
Мөселманны берсен-берсенә.
Кардәш-ыруг кайсы башын салган
Һәм хыянәт иткән үзенә.

Бер ишләре динен, хак, намусын
Алыштырган урман, җир-сугa.
Әйтерсең лә морза мохтаҗ булган
Киң Урдада дала, басуга.

Аң-акылын, җирен, динен саткан,
Илен сатып, җанын саклаган.
Читтә абруй, шөһрәт казанса да,
Барыбер дә мәхлук саналган.

Шул гавәмнең бүген варислары
Кан койдыра, сала җәбергә.
«Без бүленмәс ватан — Рәсәй» — диеп,
Ил улларын кертә кабергә.

Котырынган явыз ярсый-ярсый
Афәт, үлем илтә барсына.
Бүгенгенең сатлык җаннары да
Халкын сата тамак хакына.

И татарым! Уйлап, тәвәккәлләп
Каһарманлык кыл бер үзеңә!
Хаталардан сабак, гыйбрәт алып,
Язмышыңны ал үз иңеңә.

Газиз халкым! Йөгең зур булса да,
Якын итмә ятлар арбасын!
Исеңдә тот: үрләр меңгән чакта,
Йөгең белән төшеп каласың.

Һәр тарафтан татар моңы ташый,
Киләчәккә әйдәп татарны.
Колшәрифләр, олуг Мөхәммәтләр
Яу алдыннан йоклап ятармы?!

И татарым! Ишәйт сафларыңны,
Карашыңны юнәлт күкләргә.
Көрәшләргә дәшкән моңың белән
Язгы күкрәү булып күкрәргә!

Җыры белән, дәртле моңы белән
Әби-бабам әйткән сәламен.
Оныкларга, гасырларга юллыйк
Әманәтле чорлар әләмен!

Язмышка нәсыйхәт

(поэма)

Язмышлар тудырмый ялгышны,
Ялгышлар тудыра язмышны.

Зөлфәт

Бу тормышның, гаилә кормышның
Серләренә булмый төшенеп.
Шуңа кеше афәт, фаҗигане
Язмышына куя күчереп.

«Язмышлардан узмыш юк», — ди кемдер,
Кул кушырып яши, таптана.
Ялгышларын, гөнаһ-хаталарын
Язмышына сылтап аклана.

Язмышым дип, акламакчы үзен
Кеше талап, урлап йөрүче —
Барчасы да: сәрхүш, хәерчесс,
Тәнен сатып гомер сөрүче.

Берәүләрнең, әнә, тәкъдиренә
Ауга-яуга язган йөрергә.
Нәкъ шундыйлар күпмс илне-җирне,
Калдырдылар кара күмергә.

Алла аңа, имеш, җан өргәндә
Барыр юлын куйган билгеләп:
Илбасарга үткен кылыч биргән,
Җан кыярга диеп, йөз-меңләп.

Ләкин Аллаһ кеше үтерүне
Котсыз һәлакәткә тиңләгән.
Дөньялыкта изге гамәлләр кыл,
Җәннәтемә ачкыч шул, дигән.

Изге Коръән — язмыш күрсәтмәсе,
Гамәл кылу — кешс кулында.
Яхшы-яман юлны сайлаганда,
Кеше азат гомер юлында.

II

Кан-яшь түгә, мин бәхетсез дия,
Белми нидән газап чиккәнен, —

Ул теләгән тормыш үз кулында,
Тәртип, тәүфыйклыкта икәнен.

Безгә яшәү Аллаһ тарафыннан
Язмыш белән бергә бирелә.
Тик кешенең тормыш кормышлары
Үзе тарафыннан үрелә.

Берәүне дә көчләп, күзен бәйләп,
Ятлар кочагына салмыйлар.
Егет-кызны, кыз егетне сынап,
Ышанычлы затны сайлыйлар.

Бисмилласыз, хәер-фатыйхасыз
Өйләнешкәннәрдә тамаша.
Җан сафлыгын җуйган егет-кызлар
Кемнән гаеп эзләп маташа.

Әхлаксызлык узды чик-чаманы,
Җир сыкрана, күкләр ярсына.
Һәлакәттән йолып алыр, өчен
Нух көймәсе җитмәс барсына.

Талаш-ызгыш, көнлекчелек көне —
Мәхәббәтнең кара шәүләсе.
Хиссез генә яши алмый шул ул,
Төссезләнә Алла бәндәсе.

Ләкин мөэмин-мөселман дәүләттә
Тату яшәү гади күренеш.
Никахлашкан күркәм гомер сөрә,
Юк асрылу, юктыр бүленеш.

Никах-килешүдә алты талап
Канун булып ята нигездә.
Дин, мал, нәсел, һөнәр, гыйлем, холык —
Камил булса, яклар бер сүздә.

Күкләр хәер-фатыйхасын бирми,
Җирдә изге никах укылмас.
Үзен сөйгән парларны да Аллаһ
Рәхмәт-шәфкатеннән ташламас.

Табыштырган һәм ул кавыштырган
Егет-кызның юлы такырдан.
Гаиләдә шыткан саф мәхәббәт
Мәңге балкыр, булып бакыйдан.

Тыйнак, сабыр, итагатьле калыр
Ир хатыны булган кәләш тә.
Чын ир кеше гаиләсен саклар,
Гаилә өчен булыр көрәштә.

Шулай гомер иткән әби-бабам,
Әти-әни димләп кавышкан.
Бер-беренә тугырыклы булып,
Гомер бус сөю алышкан.

III

Катнаш гаилә корып, денссз булып,
Татарларның корый нәселе.
Тел, милләтен, дин-иманын сату —
Татар егет-кызы кәсебе.

Катнаш гаилә ул — тик мираж-рәшә,
Ике милләтара ызаны.
Шул иясез ызаннарда үсә
Чүп үләне, азган-тузганы.

Урамнарда, вокзал, подвалларда —
Өйләреннән качкан балалар.
Әти-әниләре була торып,
Нигә сукбайлыкта соң алар?

Нигә әле мескен бу нәниләр
Интегүгә дучар ителгән?
Наркоманнар, сәрхүш әти-әни
Сабыйларны ятим иттергән.

Кыйтгаларны афәт урап алды,
Һәр җанның бар борчу, сагышы.
Бер ана каз бәбкәләрен җуйган,
«Кыйгак-кыйгак», — казлар тавышы.

Анда-монда йөгерешә алар,
Югалтканын эзли казлар да.

Казлар көзен оя югалтсалар,
Ә кешеләр — көзен, язлар да.

«Кыйгак-кыйгак!», — үзәкләрне өзгеч,
Авазлардан һава тетрәнә.
Катнаш гаилә — чишмәсез елга,
Дымсыз туфрак чүлгә әйләнә.

IV

Барча дус-иш, туган-тумачаны
Сөендереп яши ир-хатын.
Аллаһыга шөкерана кылып,
Уртак итеп, булган юк-барын.

Шалтырамый юкка савыт-саба,
Сөю дә бар кебек, ара да...
Һәм бер көнне гаилә күкләрендә,
Ник соң әле болыт кабара?

Чәлпәрәмә килгән «үрнәк» гаилә,
Бәгырьләрне юа күз яше.
Юкса, бергә гомерләре үткән
Пенсиядә хатын, ир кеше.

Нинди генә көчләр, нинди кодрәт
Аерды соң ипле бу парны?
Әллә ирнең, әллә хатынгамы
Сөйләгәннәр гайбәт, юк-барны?

Кемгәдер үч итеп, ачу тотып,
Өйләнешкән парлар булганмы?
Әллә ирдә, әллә хатынында
Купкан азгын хисләр бураны?

Хатын-ирнең, әллә ир хатынның
Пычрак хыянәтен белгәнме?
Балаларны ятим итмим диеп,
Тешен кысып кына түзгәнме?

Нинди гөнаһ шомлыклары өчен
Язмыш дигән кодрәт җәзалый?
Ир — хатынны, ана-балаларны
Нинди көчләр шулай аралый?

Җил исмичә генә яфрак очмас,
Утыртмасаң, үсми иген дә.
Шарлар да бит һава тулса гына,
Атып шартлый ахыр чигендә.

Тән ярасы берчак төзәлсә дә,
Җан ярасы кала гомергә.
Ятим итмә, бала, оныкларны
Аерылып картлык көнендә.

V

Яшәү, язмыш Аллаһ тарафыннан
Изге ният белән бирелә.
Һәр кешенең тормыш корышлары
Үзе тарафыннан үрелә.

Җир-Анада без нибары — кунак,
Тыйнакларга кадер, сый-хөрмәт.
Нәфесләнми, хәрәмгә керешми
Яшәүләрдә бәхет, бәрәкәт.

Мал-мөлкәтле булу — ярты бәхет,
Хикмәт — барны тота белүдә.
Шул барыңның игелеген күреп,
Җирдә шәхес булып йөрүдә.

Дус-ишләреңнең, туган-тумачалар
Җыелышып килсә янына,
Якыннарның җылы карашлары
Сихәт бирер, балкыр җаның да.

Шалашны да берәү җәннәт саный,
Ярашканы булса кырында.
Кояш көлә, сандугачлар сайрый
Күңел тыныч булган чагында.

Ни мәгънә бар посып яшәвеңдә,
Затлы ризык белән тукланып.
Яшәр чакта рухи ризык табып,
Һәрбер яңа таңга сокланып.

Күңеле пакь, йөзе дә ак кеше
Кемнәрдәндер куркып яшәми.
Яхшы кеше үзен һәлак итәр
Яман, явыз эшләр эшләми.

Шул тормышны язмыш дисеңме син?
Ә мин әйтәм: нәфес сазлыгы.
Кешеләрнс бөск шәхсс иткән
Рухи байлык, күңел байлыгы.

«Язмышлардан узмышлар юк»,— дисп
Сыкранадыр ялгыз бер хатын.
Чирек гасыр бергә гомер иткәч,
Ташлап киткән җефет ир-затын.

Йә әйт, Хаким! Нинди сихри көчләр
Аера соң тиңдәш парларны?
Югыйсә бит гомерлеккә дисп,
Никахлыйсың сөйгән ярларны.

Нинди кодрәт, нинди илаһи көч
Мәхәббәткә каршы торырлык?
Җаны-тәне белән береккәнне
Яңа баштан сүтеп корырлык?

Бер күрүдә гашыйк булу — гөлнең,
Бер тәүлеккә чәчәк атуы.
Балкып торган чәчәкләрнең иртән
Җир өстендә шиңеп ятуы.

Гөлләр кебек гыйшык балкыса да,
Еллар буе килә ярату.
Тик хатын да, ир дә берәү генә,
Апсыз тору — гомер озату.

Тәүге хатын, тәүге ирнең генә
Мәхәббәте затлы, мәһабәт.
Яшьлекнең саф, изге хисләренә
Вәгъдәләргә итмик хыянәт.

Һәр савытның үз капкачы була,
Югалуы аның — фаҗига.
Ямаулыкны сүрү ертыгына
Яраштырып ямау могҗиза.

Тауга карап кына тау булмыйлар,
Вакыт исраф итмә, Син Адәм!
«Әгәр кеше үзе үзгәрмәсә,
Аны, — дигән Аллаһ, — үзгәртмәм».

VII

Язмышына кеше үзе хуҗа,
Үзе яза тормыш әсәрен.

Кайчак аны читкә тайпылдыра,
Чит кешеләр тыкса каләмен.

Ләкин язмыш, безнең көнкүрешләр
Ил тормышы белән бәйләнгән.
Бу икенең, җан белән тән сыман
Язмышлары бергә төйнәлгән.


Бер үк илдә, бер үк җирдә торган
Төрле кеше, төрле язмышта.
Кемдер үзен бик бәхетле саный,
Җитмәсә дә нидер тормышта.

Ярлы илнең була зур байлары,
Бай илдә дә ярлы юк түгел.
Казна малын урлап, кеше талап
Баеп китә кеше бик җиңел.

Тик берәү дә читтә кала алмый
Ил еласа, афәт кичерсә.
Бай илне дә һәлакәткә илтә,
Әдәп-әхлаксызлык үрчесә.

Киек каз юлының йолдызлары
Җемелдәве аңны сихерли.
Ләкин Аллаһ һәм илаһи акыл
Барыр юлны дөрес билгели.

V



Бәхет өчен күпме кирәк?..

Мин бәхетле

Ничек кенә салкын сарылмасын,
Чеметмәсен борын очларын...
Барыбер дә урман яз кояшын
Каршы ала, җәсп кочагын.

Туңны ерта, умырзая шыта,
Тамырлардан ага җир мае.
Ямьле яшел күлмәк кия урман,
Гүзәллеккә чума май ае.

Аланнарда пешә сусыл җиләк,
Кояш нурларына төренеп.
Җемелдәшә энҗе бөртекләре,
Үлән арасына сибелеп.

Аллы-гөлле шушы чәчәкләрдән
Һәр тарафка хуш ис бөркелә.
Тиңсез-чиксез яшерен могҗизаның —
Ис-төсләрнең серен кем белә?

Урманнарны иңләп моң агыла,
Өздереп лә сайрый кошлары.
Мәхәббәтең монда канат кага —
Өтеп ала ялкын-утлары.

Бер карасаң, гүзәл, бер карасаң...
Урман эче хәтәр шикелле.
Саташтыра сине, адаштыра,
Үзе шомлы, үзе сөйкемле.

Урманнар да — нәкъ кешеләр кебек,
Шундый серле, шундый тылсымлы...
... Бер әйләнеп кайтсам урманымны,
Мин — бәхетле, җырлы, мин — моңлы!

Урман

Ничек кенә салкын тырышмасын,
Өшетмәсен борын очларын
Табигатьнең үз кануны катгый:
Яз елмая җәеп кочагын.

Шытып чыга тәүге умырзая,
Һәр үсемлек таба үз җаен.
Дөнья чума сихри гүзәллеккә,
Яшеллеккә төреп май аен.

Аллы-гөлле болын чәчәкләре
Йөгереп чыга сыман каршыңа.
Әсир итә гөлләр нәфислеге,
Чүгәлисең барып карпына.

Ямь өстенә тәмле сый өстәлә —
Җиләк белән тулы яланы.
Табын җәеп, гүя каршы ала,
Чия, шомырт, миләш, баланы.

Сихәт керә тәнгә, саф һавасын
Сулаганда күкрәк тутырып.
Сый-хөрмәтле, мәгърур, мәһабәтле
Агачлары тора утырып.

Менә чыршы. Күр, никадәр горур,
Әйтерсең лә, купшы абыстай.
Янәшәдә имән пәһлеваны —
Сабан туйда батыр калыштай.

Сөбханналлаһ, нарат сылукайның
Зифа булып үскән буй-сыны.
Ак күлмәгеп киеп, көлеп тора,
Хур кызыдай чибәр каены.

Изү чишеп, күкрәген киереп,
Җәелеп үскән иңле карама.
«Көч-куәтем сынмас бормаларда,
Буема, — ди — минем карама».

Кураҗиләк, тәмле җиржиләкнең,
Авызында хушын тотарлык.
Изрәп пешкән алан җимешләрен
Бер кашыкка салып йотарлык.

Урманнарның, хатын-кызлар кебек,
Әсир итә сихри тылсымы, —
Алар кебек серле, мавыктыргыч,
Һәр агачның үзгә буй-сыны.

Бер карасаң — гүзәл, бер карасаң...
Урман әче хәтәр шикелле.
Адаштыра, кыйбла саташтыра,
Үзе шомлы, үзе сөйкемле.

Һәм шәфкатьле, юмарт, мәрхәмәтле,
Игелеклек иңгән уена.
Күркәм холык, садә сыйфатлары
Бизи аны гомер буена.

Олыгайган саен фидакарьлек
Гамәлендә ныграк ашкына.
Җил-давылдан саклап, ала каплап,
Мохтаҗларны канат астына.


Дан-шөһрәткә һич тә мохтаҗ түгел,
Урман — үзе галим, зур даһи.
Тудырган да, үстергән дә үзе —
Җир-Ананың кызы — Илаһи.

Әнә, көз дә инде якынлаша,
Чуарланган аның бизәге.
Йөзен үзгәртсә дә, иманында,
Асылында кала үзәге.

Чыршы, нарат үзе булып кала,
Төсен-битен, холкын үзгәртми.
Нәсел-нәсәбенә сары сагыш
Китерә торган төсләр ияртми.

Иңнәренә салган яшел шәлнең
Ап-ак карлар кунган чугына.
Тышта февраль. Салкын. Ләкин урман
Сәфәр чыккан язлар ягына..

VI



Дүртъюллыклар

* * *

Ерак бабам, белмим, кем булгансың?
Болгармы син, Хәзәр, башкамы?
Гүзәл телем, динем, моңым бәлән
Мин татармын! Белмим башканы!

* * *

И, әнием, чиккән михнәтләреңнән
Җиде буыннарга җитәрлек.
Сез яшәгән чорның газаплары —
Җилегеңә кадәр үтәрлек.

* * *

Әй, онытым, син — улымның улы,
Бер карасаң, варис та кебек.
Ләкин синең анаң тамырында
Илбасарлар каны ага бит.

* * *

Аттан ала да, кола да туа,
Син шуларның кайсы төследер?
Бисмилләле йортта туган булсаң,
Иншалла, хаклык өстендер!

* * *

Һай, татарым! Акылың томалаган
Нәфесеңә тап соң бер әмәл.
Көнләшүне, үчлек, хәсетлекне
Авызлыкла, кыл бер эш-гамәл.

* * *

Күңел күгенең инде юк,
Яхшылыкның юк чиге.
Алла рәхмәтедә чиксез,
Юк аның һичбер тиңе.

* * *

Эте-бете акыл сата,
«Мин!» — диярга ярата, —
«Колак кисеп, тишек яма», —
Дип вәсвәсә тарата...

* * *

Хатын ашар кара ипи,
Сөяркә-чәйгә тәм-том.
Иписсэ син яшәп кара!
Тәм-том җитә бер йотым...

* * *

Кибән кадәр ана дуңгыз,
Хәрам аның исеме.
Хәрам ашап дуңгыз була
Динсез татар нәселе.

* * *

Берәү әйтә: «Арабызда
Ни аерма күрәмсең?»
Ә мин әйтәм: «Кем — оҗмахка,
Кем — тәмугка керәсең...»

VII



Көй көткән шыбырь

И, татарым!

(җыр)

Далада ат чапкан, җиһанда бил тоткан,
И, болгар, бөек һун токымы!
Көч-куәт индерсен, рухыңа дәрт бирсен,
Шөһрәтле үткәннәр ялкыны.

Кушымта:
Идел-йорт үз илең, кыр-дала үз җирең,
Яшә син ил-җирдә бердәктә.
Гайрәтле бул, татар! Хөрмәтле бул, татар!
Шатланып гомер ит хөрлектә.

Муллыкта коеныл, яшә син ил булып,
Иминлек, игелек терәге.
Көрәшкә өндәсен, җиңүләр китерсен
Каһарман бабаңнар үрнәге.

Кушымта.

Горур бул син, татар! Тәвәккәл, кыю бул!
Язмышың булсын үз кулыңда.
Дәүләтең нык булсын, иманлы ил булсын
Аллаһның рәхмәтле юлында.

Кушымта.

Берләш, татар!..

Явыз дошман илне таптап үтте,
Тагып шомлы коллык тамгасын, —
Татарларның затлы дәүләтләрен,
Тар-мар итте — Алтын Урдасын.

Кушымта:
Дунай белән Иртеш аралары —
Ата-бабамнарның ватаны.
Үз илендә җәбер-золымнардан
Аралар тик татар татарны.

И гайрәтле, көч-куәтле татар!
Бил алышыр заман дөньяда.
Гасырлардан килгән игелекле
Батырлыгың күрсәт мәйданда!

Кушымта:
Дунай белән Иртеш аралары —
Татарларның газиз ватаны.
Илбасарның коллык богавыннан
Азат итәр көрәш татарны.

Берләш татар! Синең чорың килде,
Изге фәрман инде Алладан.
Торгыз данлы-шанлы дәүләтеңне,
Иленә бул хуҗа яңадан!

Дунай белән Иртеш аралары —
Кайарман бабаңнар җирлеге.
Дөньяны иңләгән татарның
Ныгысын татарлык берлеге!

И, Казаным

(җыр)

Чал тарихның давылларын кичеп,
Яктылыкка һаман үрләдең.
Йортың-җирең яулар җимерсә дә,
Дошманнарга башың имәдең.

Кушымта:
Кыйтгаларның торып уртасында,
Дуслык таҗы булып балкыйсың.
Хак юлыңнан ерак дәверләргә,
Асылында торып атлыйсың.

Гасырларның дәрте, көч-куәте,
Синдә — бөек Дала кодрәте.
Болгар, хазар, кыпчак варисларын
Берләштерде татар милләте.

Кушымта.

Татар Иле Сине байрак итеп,
Чорлар аша җиңеп үтәчәк.
Горурланып дистә меңъ елыңны,
Оныклары бәйрәм итәчәк.

Кушымта.

Әнкәмнең күркәм йөзе

(җыр)

Кунак килсә, келт итә дә,
Әнием искә төшә.
Ак җәймәдә — ак самавыр,
Табада коймак пешә.

Куплмта:
Ак җәймәдә ак самавыр,
Әнкәмнең күркәм йөзе.
Сөтле чәенә тәм биргән
Хак әйткән ихлас сүзе.

Сый-хөрмәт итте кунагын
Барын табынга куеп.
Әңгәмә корды кунакның
Эчке халәтен тоеп.

Кушымта.

Әйтә иде: «Кунак өйгә
Ризыгы белән керер.
Аның өлешен хуҗага
Аллаһы үзе бирер».

Кушымта.

Балкып торсын йөзе ярларның

(җыр)

Сулар кире акмый, үткән кайтмый,
Кадерен белик, янда булганның.
Дус-туганнар бергә, меник үргә,
Уң булуын телик юлларның.

Кушымта:
Сөелеп һәм сөеп, тиңем диеп,
Тату яшәүләргә ни җитә?
Кояш кебек көлеп, назга төреп,
Иркәләүне күңел гел көтә.

Тормыш тәмен белеп, ямен күреп,
Гомер итүләрдә бар хикмәт.
Өебездә һәрчак, яна учак,
Дус-ишләргә кадер, сый-хөрмәт.

Кушымта.

Балкып торсын нурлы, шатлык тулы
Күркәм йөзе газиз ярларның.
Чиксез бәхет үзе, күңел күзе
Гүзәллеген тойса дөньяның.

Кушымта.

Гомерлеккә

(җыр)

Язгы гөрләвекләр идек,
Сөю күленә чумдык.
Тормыш диңгезендә йөзәр
Парлы дулкыннар булдык.

Кушымта:
Җитен җеп булып эрләнә,
Тукымага әйләнә.
Уй-ниятләр хак булганнар
Никах-туйлап өйләнә,
Гомерлеккә бәйләнә.

Сөю күлебез саекмас,
Мәхәббәтебез арта.
Сабыр төбе — сары алтын,
Күңел түрендә ята.

Кушымта.

Кысыр вәгъдәләр түгелдер
«Яратам сине» — дию.
Әбелхәят диңгезендә
Сөю көенә бию.

Кушымта.

Хәбибә

(җыр)

Акыл китте, гашыйк итте
Күрше кызы Хәбибә.
Мәхәббәт тулы йөрәгем,
Хә-би-бә, диеп тибә.

Кушымта:
Хәбибәкәй, мәхәббәтем
Кабынмады сүнәргә.
Телим, кочагыма алып,
Бердәнберем, дияргә.

Яратуымны яшереп,
Сер итеп саклап йөрим.
Мөлдермә хисләремне,
Үземә-үзем сөйлим.

Кушымта:
Хәбибәм, — дим, — мәхәббәтем
Кабынмады сүнәргә.
Мәхәббәтемә уралып
Йөрим охшап юләргә.

Тәрәзәләренә карыйм,
Пәрдәләрдә таң нуры.
Пәрдә читендә елмая
Хәбибәм — нурдан нурлы.

Кушымта:
Хәбибәкәй, мәхәббәтем,
Кабынмады сүнәргә.
Мәхәббәт мәңгелек диләр,
Телим мәңге сөяргә.

Тәүге мәхәббәт ялкыным
Җитәр соңгы көннәргә.

Ак күбәләк

Ф. Хатыйпов кое

Коръән уку мәҗлесенә
Якын туганнар килде.
Өебезгә нурлар сирпеп,
Ап-ак күбәләк керде.

Кушымта:
Ак күбәләк — нур күбәләк
Әй шатлана, сөенә.
Хәер-фатыйха өләшә,
Канатын җилпеп кенә.

Өй түрендә ак күбәләк
Газиз әнием җаны.
Үзе кайткан кебек булды,
Сөендек күреп аны.

Кушымта.

Изге хәер-догаларны
Аллаһы кабул кылсын.
Җәннәт әһеле булырга
Әнкәмә насыйп булсын.

Кушымта.

Хикмәт

Күршебездә бер пар яши
Никахлы гомер сөреп.
Кая барсалар да бергә,
Соклана читләр күреп.

Күршем әйтә: «Хатыным, ди,
Беренче ирен сөя.
Үзе мине яратам, ди,
Тегене «ирем!» дия!

Тату торабыз шикелле...
Хатын көлә, шаяра.
Бер карасаң, тормышыбыз
Майлаган кебек бара.

Аш-су мулдан, урын түрдән,
Көнләшә күргән-белгән...
Хатын минем белән йоклый
Тик яши ире белән!»

Ялгышты

Динем өчен түгел, көнем өчен,
Диеп татар дуңгыз үрчетә.
Сарыкларын суеп, тунын ягып,
Бу бичара беткә үч итә.

Дуңгыз ите сатып, хәмер йотып,
Татар кайтып килә, күңле шат.
Һаваларда торна очып бара...
Кемдер орды башка җан сорап...

Хәрәм акча торна булып очты,
Тунын ягып татар ялгышты!..

Алдану

Тавыгы озак утырып,
Чыкмагач чебеш,
Аптыраган хуҗабикә:
«Бу соң ниткән эш?»

Тавыгың астына куйсаң,
Чәберчек күкәй.
Үзең төп башында торып,
Калырсың түтәй.

Эт чаба дип...

Яшь кенә сарык бәтие
Ярты лаш шәрә калып,
Көпрәеп ул атлап килә,
Койрыгын сыртка салып.

Үрле-кырлы сикергәли,
Арт санын чайкап ала.
Үз ишләре «кәттә» диеп:
Көнләшеп карап кала.

Боргалана-сыргалана
Яшь тәкәләрне күреп.
Имчәкләре күренсенгә
Ботларын куя ерып.

Кәперәеп атлап бара
Арт аякларда торып.
Бил, кендек тирә ялангач,
Алдырган йонын кырып.

Эт чаба дип, бст чаба
Бәтиләр ярымшәрә.
Кызлар, бу сезгә ишарә,
Йөри күрмәгез шәрә.

VIII



Дөнья бу!

Хикәят

Батып барган күк кояшын урлап,
Хуҗа булмак булган бер дәдәй.
Җәтмә аткан алсу офыкка ул,
Алтын кояш кереп китәрдәй.

Үз исемен таккан урман, кырлар,
Далаларга, елга, күлләргә,
Дәрьяга тиң кан, яшь агызып,
Басып алган җирләр, илләргә.

Диңгезләрне, океан суларын
Һәмдә барча биләмәләрен,
Каратмакчы булган тик үзенең,
Халкы яши торган җирләрен.

Хөр кояшны хезмәтчесе итеп,
Кушмак булган эшнең барчасын.
Мич башында ятып, уктан атып,
Кәләш итмәк- күлнең бакасын.

Ләкин җәтмә дөрләп янып бетә,
Дәдәй сырхау ала тәненә.
Бу мәкергә бик рәнҗегән кояш
Йөзеп китә Галәм түренә.

Эт көнендә

Сак этенең рәте китте,
Тешләре төшеп бетте.
Барлы-юклы нигъмәтеннән
Хуҗасы мәхрүм итте.

Ырылдаса, каршы өрсә,
Томалыйлар авазын.
«Ишегалдында без хуҗа», —
Дип ябалар авызын.

Урам этләре картлачны
Утырталар «акылга».
«Босска койрык болгамасаң,
Ояң тарыр ялкынга».

Карт эт нәтиҗә ясады:
Боссның табанын ялый.
Берни күрми, ятка өрми,
Үз җаен гына карый.

Яхшы-яман

Аттан ала да, кола да
Туа бертуган булып.
Яхшы-яман да бертуган,
Дөнья булганнан алып.

Агай-энеле бу икәү
Һаман бергә тормышта.
Көн белән төн кебек алар,
Аерылмыйлар карыш та.

Яхшының һәрбер адымын
Яман сагалап тора.
Бер мәлгә яхшы ялгышса,
Ул аны алмаштыра.

Дөньяда һәрнәрсә парлы,
Яшәү шуңа корылган.
Яхшы кадерен белергә.
Яман сакка куелган

Алар шулай гомер буе
Кешегә сабак бирә
Әле яхшы, әле яман:
Безнең белән көн күрә.

Яхшылык та, яманлык та
Гыйбрәтләр алыр өчен.
«Сабыр төбе — сары алтын»,
Аллаһ сабырлык бирсен.

Хәер сорый

Арык кулын сузып, хәер сорап,
Агай тора базар чатында.
Уйламаган ач-ялангач калу,
Мәсхәрәле картлык хакында.

Ап-ак йөзле агай басып тора,
Күкрәгендә орден, медале.
«Победитель пятилетки» дигән,
Нишаны бар — яшьлек гамәле.

Гомер буе маңгай тирен түккән
Хәер сорый хәлсез ветеран.
Ашарына ашы булмаганнар
Җиде юл чатына утырган.

Мәнсез затлар илне таркаттылар,
Төп башына халкын утыртты.
Капиталның кыргый базарына,
Котсыз мәхшәренә ыргытты.

Кыргый базар

Күз тигән бала күк булды,
Кинәт чырае китте.
Төс-кыяфәте үзгәрде,
Ил бетәр хәлгә җитте.

Гөрләп торган завод-фабрик
Лып итеп туктап калды.
Йөз-меңләп эшче-хезмәткәр
Урамнар белән тулды.

Үлемтеккә дип җыелган
Акчалар бетте «янып».
Сәүдә итеп көнкүрегә
Базарга күчте халык.

Әдәп-әхлак, оят-намус
Сатыла шул базарда.
Пенсия акчасы җитми
Ипи, сөт алырга да.

Ач-ялангач пенсионер
Утыра башын кашып.
Әби-бабай калды шулай
Тешсез, авызын ачып.

Шылт иткәнне

Шылт иткәннән суга чумган
Баканы күреп куян:
— Бу мин, батыр абзаң! — диеп,
Күкрәген сугып куйган.

Куян шикелле мактанчык
Абзыкайлар бездә бар.
Телләре тегермән тарта,
Күкрәкләре ләкин тар.

Чын бәхет — бәрәкәттә

Туплар ата, ут уйната...
Нәни ил канга баткан.
Җир-су даулап килгәннәрнең
Күпләре әҗәл тапкан.

Өлкән агайның нәфесе
Меңь ел инде мал җыя.
Ач халык өшеп-туңса да,
Сугышка корал коя.

Әни мәрхүм әйтә иде:
«Чын бәхет — бәрәкәттә.
Тик аны манчысаң канга,
Китерер һәлакәткә».

Шуны сөйли Чечня җиле
Азаплы иртәләрдә.
Ачы язмыш көтә сузсаң,
Канлы кулың әгәр дә...

Атла, болынга таба

«Түгәрәк өстәл» тирәли
Агай-әне утырган.
Иманын, илен, милләтен,
Үзен дә сата торган.

Талашып калҗа йолкыйлар,
Табында татар башы.
Башның аң-хәтерен барлап,
Акылын җыйган чагы.

«Идел-йорт Илбашы булып,
Мәскәүле, — диләр торсын.
Кирәк түгел мөстәкыйльлек,
Вертикаль властъ булсын».

Тамада агай кул чаба
Телләрсенә май яга.
«Бис, молодец», — дия-дия,
Тамырларга чәй кага.

«Өлкән туган» кан-кардәшне
Бүлгәли бөрәм-бөрәм.
Хәйлә, мәкер җәтмәсендә
Ханлыклар булды әрәм.

Хуҗасы табынын ялау,
Тезләнгән коллар эше.
Милләтне, дәүләтне сатты
Иванга шулар ише.

«Син дә мулла, мин дә мулла
Атка печән кем сала?»
Чык араннан, милләт аты!
Атла, болынга таба!

Әтәч

«Таң әтәчләре кычкыра,
Әллә таң ата микән?»
Халык җыры

Таң әтәче булып берәү,
Яңгырау аваз салды.
Күрше-күлән әтәчләре
Сагаеп, тынып калды.

Шул әтәчнең һәр авазын
Тыңлыйлар авыз ачып.
Чөнки үзгә тавышлылар
Бетте таралып, качып.

Ул акыллы, аң-белемле
Булдыклы, саллы, — диләр.
Зурлый, мактыйлар әтәчне,
Зирәк тә, дип сөйлиләр.

Төс-кыяфәте белән дә
Ким-хур булырлык түгел.
Сын-гәүдәсе сыгылмалы,
Йөреше дәртле, җиңел.

Уй-фикере изгелектә...
Эшләргә дә эшләргә.
Ишек алды улагына
Саф су кирәк өстәргә.

Таң белергә, көн күрергә
Үз әтәчебез күркәм.
Ялгышып куйса да, кайчак
Кирәкми безгә бүтән.

Әйләнеш

И, гомеркәй, болыт арасыннан
Балкып чыккан кояш шикелле,
Ялт иттең дә, инде йомыласың,
Ак нурларың җиргә сибелде.

Кеше дигән затны миллион еллар
Иҗат иткән Кодрәт иясе.
Җир йөзендә юктыр аңа тиңнәр,
Дөньяларда юктыр тиңдәше.

Сокландыргыч шушы адәми зат
Комсызланып җыя мал-мөлкәт.
Ул тәккәбер. Имеш, акыллы зат
Һәм бер мизгел... алда — һәлакәт.

Галиҗанәп вакыт һәм бер мизгел
Кемдер туа, кемдер юк була.
Тән туамы, җан туамы бүген,
Йа Иләһым, әйтче, кем туа?

Һәм ул булыр нинди кыяфәттә,
Калырмы ул Кеше төсендә?
Нинди гамьнәр аны әйдәп йөртер,
Ни майтара алыр эшендә?

Ахирәттә беркем колач җәеп,
Чәк-чәк тотып безне көтмидер.
Һәм берәү дә, ашап-эчми генә,
Эш-гамәлсез гомер итмидер.

Хак Тәгалә безгә акыл биргән,
Үз көнеңне үзең күр, дигән.
Мәңге яңәспкә юл күрсәткән,
Изге китапларын индергән.

Җәннәттә дә акыл һәм хис булса...
Бу дәвамы, димәк, тормышның.
Маңгайларга алдан язылгандыр
Һәр гамәле безнең язмышның...

Аллаһ безгә серле мәгънә салган,
Акыллы һәм асыл зат кылып.
Юкса, яшәр идек ерткыч булып,
Йә кемгәдер азык, аш булып.

Ә без — Кеше. Адәм, җиргә килеп,
Тау-ташларда тормыш башлаган.
Җир-Ананы сөеп, рәхмәт, диеп,
Зиһен, белем, фикер туплаган.

Иксез-чиксез Галәм бакый икән,
Тормыш вә Яшәеш мәңгелек.
Сулар да бит, парга әйләнә дә,
Җиргә ява яңгыр, кар булып.

Бу — илаһи вакыт әйләнештә,
Бар нәрсә дә тора алмашып.
Яшәешнең серле агымында
Калма, кешем, калма адашып.

Туган тел

И туган тел, и матур тел,
Болгар бабамның теле.
Сүзнең гүһәрләре белән
Бизәде халкым сине.

И туган тел, и матур тел,
Бабаларымның теле.
Була күрмә оныкларның
Син ятим, үги теле.

И туган тел, и матур тел,
Халкымның үлмәс даны.
Үзеңне саклаган кебек
Сакла син, татар, аны!

И туган тел, и матур тел,
Әткәм-әнкәмнең теле.
Син яшәсәң, мәңге яшәр
Данлыклы татар иле.

ЭЧТӘЛЕК

Шатлык бүләк итә алуда, башны гамьгә сала белүдә чын бәхет 3

Васыять

Васыять 10
Оныгым Шамилгә 11
Күцел очынганда 13
Соң түгел! 14
Алга, иреккә табан! 15
Биш тирәк 16
Юк!.. 17
Гарасат 18
Үзгәртәсе иде 20
Өмет итик 22
Әй, бу гомер... 23
Иншалла 25
Үзең төшәсең 26
Авылым 27
Асылыца кайт, татар! 28
Табигатьнең үзе, гел үзе... 29
Акыл белән яшәргә 30
Әни талган үлем йокысына 32
Йомычка 33
Кыз-әби 34
Дөнья булгач... 35
Бар да әйләнештә... 36
Тудырган да, үстергән дә... 37
Язмышлардан узмыш... 38
Аш ашадым, яшь яшәдем... 39
Тау гомере теләп 40

Сәер төш

Җирдәге кояш 42
Мәхәббәткә генә гөнаһ юк... 44
Минем иркәм 46
Соңласа 48
Сәер төш 50
Бел 49
Ялгызлык 51
Хуш — бәхил бул 53
Тамчы гөлең, ак яулыгың 55
И язмыш, язмыш 56
Өмет итәм 58
Сизмәдем китәсеңне... 59
Юксыну 60
Үзең йөрәк түрендә 62
Юк, һаман да ышанасым килми 64
Ак яулыгың хаҗ яулыгың 66
Юк сыман 67
Шөкер итәм 69
Алмаш та юк, тиңдәш тә... 70
Җыр — мәрсия 71
Исраф иттең 72

Һәркемнең үз тиңе

Һәрчак тигез бул син 74
Һәлакәт 75
Белсен! 76
Ишетелә... 77
Җилләр исә 78
Ике куен 79
«Бер ягында күкнең кара болыт...» 80
Бик тә кирәк чак 81
Табышу 82
Кызыл китап 83

Сәерләрдән сәер җан 84
Җиде күктә 87
Эт типкәсе 88
Дөньясы — эт оясы 89
Санга бар, исәпкә юк 90
Кара эт бәласе — ак эткә 91
Күке балалары 92
Бусагада ана... 94
Бик күңелсез бер чакта 96
Албасты 97
Нәсыйхәт 98
Бер фатирда ике ялгыз 99
Сәрхуш 100
Хикәят 101
Карбыз һәм чикләвек 102
Бәрелеш 104
Хуҗа булып китмәкче 105
Афәт 106
Троллейбуста 107
Нинаять 108
Татар таеп егылмас 111
Мөселманнар берләшегез! 113
«Ап-ак чәчәк атты бадьян...» 114
Язгы хисләр 116
Һәркемнең үз тиңе 117
Чәчәк атыр 118
Кочты 119
Ил-җир — утлы тәбада 120
Белеп тор! 121

Йә, әйт кеше!..

Ташлар сере 124
Йә, әйт, Кеше! 133

Иң югары бәһа 140
Ана 160
И хатын-кыз!.. 172
Багышлау 181
Моң 191
Язмышка нәсыйхәт 202

Бәхет өчен күпме кирәк?..

Мин бәхетле 214
Урман 216

Дүртьюллыклар

«Ерак бабам, белмим, кем булгансың?..» 220
«И, әнием, чиккән михнәтләрең...» 220
«Әй, оныгым, син — улымның улы...» 220
«Аттан ала да, кола да туа...» 221
«Һай, татарым! Акылың томаланган...» 221
«Күңел күтенең иде юк...» 221
«Эте-бете акыл сата...» 222
«Хатын ашар кара ипи...» 222
«Кибән кадәр ана дуңгыз...» 222
«Берәү әйтә...» 222

Көй көткән шигырь

И, татарым! 224
Берләш, татар 225
И, Казаным 227
Әнкәмнең күркәм йөзе 228
Балкып торсын йөзе ярларның 229
Гомерлеккә 230
Хәбибә 231
Ак күбәләк 233
Хикмәт 234
Ялгышты 235

Алдану 235
Эт чаба дип... 236

Дөнья бу!

Хикәят 238
Эт көнендә 239
Яхшы-яман 240
Хәер сорый 241
Кыргый базар 242
Шылт иткәнне 243
Чын бәхет — бәрәкәттә 244
Атла, болынга таба 245
Әтәч 247
Әйләнеш 249
Туган тел 251

САФИН Раис Абдуллович

ОСКОЛКИ СЕРДЦА

Стихи
(на татарском языке)

Компьютерда битләргә салучы *А. Галиуллина*
Рәссам *Р. Шәмсетдинов*

Сдано в набор 03.04.2012. Подписано к печати 11.06.2012.
Формат 60x84 1/16. Бумага офсетная.
Гарнитура «Академия». Печать ризографическая.
Усл. печ. л.16. Тираж 200 экз. Заказ № 92.

Редакционно-издательский отдел ГУ «РЦМКО».
420111, Казань, ул. Дзержинского, 3. Тел. 92-24-76
Отпечатано на множительном участке центра.